• МИНБӘР •
МӨСЕЛМАН ХАТЫН-КЫЗЫ
*4 бит*

• СОРАУ-ҖАВАП •
НАМАЗ ВАКЫТЫНДА ТЕЛЕФОН ШЫЛТЫРАСА
*7 бит*

• МӘҮЛИД •
ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗНЕҢ ДӨНЬЯГА КИЛҮ КЫЙССАСЫ
*10 бит*

• ЗУР ГӨНАҺЛАР •
НАМАЗГА ИГЪТИБАР ИТМӘҮ
*12 бит*

*№ 10 (303)* *Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы* *Рабигыль-әүвәл 1442*

*Октябрь, 2020*

# دين ومعيشت

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

محمد صلى الله عليه وسلم

## المولد النبوى

## МӘҮЛИД АЕ МӨБАРӘК БУЛСЫН

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм – Җир йөзенә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез. Аңа һәрдаим салаватлар әйтеп, Раббыбызга шөкерләребезне белдереп, зикердә булып, догалар кылып яшик.

*Дәвамы 10 нчы биттә*

# Казанда мөселман уку йортлары мөгаллимнәре форумы узды



21нче октябрь көнне Казанда мөселман белем бирү оешмалары мөгаллимнәре форумы узды. Форум 2011 елдан башлап ТР мөселманнары Диния нәзарәте, Ислам мәдәнияте, фән һәм мәгариф фонды һәм Рәсәй ислам институты белән берлектә үткәрелә, мөселман мәгарифе һәм тәрбиясе өлкәсендәге мөһим мәсьәләләр турында фикер алышу һәм аларны хәл итү өчен мәйданчык булып тора. Быел әлеге форум «Хәзерге Рәсәйнең фәнни-мәгариф киңлегендә традицион диннәр теологиясе» Халыкара симпозиумы кысаларында оештырылды.

Форум Изге Коръән аятьләрен укып, дога кылудан башланып киткәннән соң, әлеге мәртәбәле җыенда катнашучыларны Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин исеменнән аның беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин сәламләде. Ул үз чыгышында мөгалимнәргә дин гыйлемен бирүдә сабыр булырга, мәчет каршындагы курсларга йөри башлаган яшьләрне игътибарга алырга, аларның әти-әниләре белән элемтәне җайга салырга чакырды. Рөстәм хәзрәт фикеренчә, мәчет каршындагы курсларга яңа гына йөри башлаган яшьләр дини постулатларны дөрес аңлап бетермичә, өендә дөрес итеп аңлатып бирә алмыйча, шуның сәбәпле әти-әниләре белән каршылыкка керергә мөмкин. Ә ата-аналарда, үз чиратында, «дин дөрес түгел икән» дигән фикер туарга һәм алар баланы мәчеткә барудан тыярга, үзара килешмәүчәнлек килеп чыгарга мөмкин. Шуларны булдырмау өчен Рөстәм хәзрәт ата-аналар белән җыелышлар уздырып, аларга яшьләргә биргән мәгълүматны җиткерергә һәм бала, курслардан өенә кайтып, дин турында сөйли башлаганда, ата-аналарның аны дөресләп җибәрерлек белеме булырга тиешлеген ассызыклап әйтте. Ул мәчет каршындагы курсларда белем бирүче мөгаллимнәргә: «Киләчәктә булган тәҗрибәне истә тотып, алга таба хаталарны җибәрмәскә кирәклеген аңлап эш итәргә кирәк», – диде. Ә инде өлкән яшьтәге шәкертләр белән эшләүгә килгәндә, Рөстәм хәзрәт, билгеле бер системага салып, тулы Коръәнне укып чыгу – Коръәнне хәтем кылу эшен башкарырга тәкъдим итте: мәхәлләләрдә потенциал бар, имамнарның бурыч итеп куюы гына кирәк.

ТР Президенты Аппаратының Эчке сәясәт мәсьәләләре буенча департаменты вәкиле, баш киңәшче Айнур Солтанов үзенең сәламләү сүзендә бүгенге көндә мәчет каршындагы курсларның тагын да актуальләшүен билгеләп үтте. «Сер түгел: дәүләт белем бирү системасында милли һәм төбәк компонентын өйрәтү буенча мөмкинлекләр чикле. Шуңа күрә үзләренең балаларын татар мохитендә тәрбияләргә, телне, динне өйрәтергә теләгән күп ата-аналар үз игътибарын мәчеткә таба юнәлтә. Мәчеттә шушы мохитне эзлиләр. Чыннан да, мөфтияткә, Камил хәзрәткә дә зур рәхмәт әйтергә кирәк, ул бу проблеманы аңлый», – диде Айнур Солтанов.

Билгеле булганча, хәзер мәчет каршындагы курсларда «Без – татарлар!» дип аталган татар телен өйрәтү курслары эшләп килә. Анда дин генә түгел, татар теле дә, татар тарихы да өйрәтелә. «Бу, безнең фикеребезчә, чыннан да, перспектив башлангыч, чөнки безнең телне, динне, төбәк тарихын белгән тулы канлы шәхесләр тәрбияләү максаты тора», – диде Айнур Солтанов, мөгалимнәрнең фидакарь хезмәт куюын, моның шактый авыр эш булуын билгеләп үтеп.

Айнур Солтанов Татарстан җитәкчелегенең Диния нәзарәтенең инициативаларын хуплап каршы алуын, һәрдаим ярдәм итеп торырга әзер булуын, бергәләп эшләп, мәчет каршындагы курсларның эшчәнлеген камилләштереп, яңа дәрәҗәгә җиткерә алырбыз, дип хәбәр итте.

Форумда чыгыш ясаган Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Мәүлид ае белән котлап, шәкертләргә белем һәм тәрбия биргәндә, иң элек әдәп-әхлак мәсьәләләренә игътибар итәргә чакырды. Барлык белем һәм тәрбия эшенең гүзәл әхлакка алып барырга тиешлегенә басым ясады. Ислам галиме Ибне Гарәбинең хикмәтле сүзләрен искә төшереп, ул: «Әгәр кешенең күңелендә Исламга карата мәхәббәт булса, аның күңелендә Ислам дигән үсентене утыртып калдырырга тырыш, ул үз җимешләрен бирәчәк», – дип искәртте. Һәм үрнәк итеп Кукмарадагы мәдрәсә җитәкчесе Ришат Курамшинның эшчәнлеген китерде. Балтач районы мәктәпләрендә әхлак дәресләрен укыту тәҗрибәсе белән таныштырып үтеп, балалар бакчаларында да, мәктәпләрдә дә Ислам диненең матурлыгын күрсәтергә кирәклеген ассызыклады. Җәлил хәзрәт, ТР Президенты аппараты вәкиле Айнур Солтановка да мөрәҗәгать итеп, дин әһелләренә грантларны шәхсән бирү мәсьәләсен күтәреп чыкты.

ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Аксакаллар Шурасы рәисе Айрат Әюпов исә мәчет каршындагы курсларны тәмамлаучыларны мәдрәсәләргә укырга җибәрү тәкъдиме белән чыкты, туган телне саклау мәсьәләләренә тукталды.

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының милли мәгариф комитеты җитәкчесе Рөстәм Гыйльметдинов үзенең сәламләү сүзендә Татарстанда дини белем бирү системасының югары дәрәҗәдә булуын һәм бу тәҗрибәне башка төбәкләргә дә тарату зарурлыгын билгеләп үтте. Ул шулай ук уку-укыту процессында цифрлы технологияләр куллану, тарихи мирасыбызны өйрәнү, дәресләрне кызыклы итү мәсьәләләренә тукталды. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисен искә төшереп, белем биргән һәм белем эстәгән мөселманнарның зур дәрәҗәгә ия булуын билгеләп үтте.

Болгар ислам академиясе мөгаллиме, профессор Исмаил Х.М. Болбол бүгенге җыен «безнең гыйлемгә булган мәхәббәтебезне күрсәтә», дип билгеләп үтте. Һәм Фәләстыйн мәчетләрендә белем бирүнең үткәне һәм тәҗрибәсе белән таныштырды. Үз җирлегендә балаларның Коръән ятлау тәҗрибәсе турында сөйләде.

Форум кысаларында ТР Диния нәзарәтенең онлайн мәдрәсә проекты, шулай ук Алабуга шәһәренең «Ихсан» гомуми белем бирү мәктәбе мисалында үсеп килүче буынга әхлакый тәрбия бирү үрнәкләре, Казандагы «Адымнар» полилингваль комплексы эшчәнлеге, «Ярдәм» милли ислам хәйрия фондының хәйрия проектларын тормышка ашыру тәҗрибәсе тәкъдим ителде. Ә мәчетләр каршында эшләп килә торган курсларның эш тәҗрибәсе белән Питрәч мөхтәсибәте Шәле авылының «Заһир» мәчете, Казан шәһәренең «Гадел» мәчете, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Лениногорск районы мөхтәсибәте вәкилләре һ. б. уртаклашты.

Форумның күркәм өлеше булып шулай ук рәхмәт хатларын тапшыру торды. Динебез һәм милләтебезнең алгы сафларында булып, нәтиҗәле эшчәнлекләре өчен, Татарстан мөфтиенең рәхмәт хаты Алабуга районы имам-мөхтәсибе Хәлим хәзрәт Шәмсетдиновка һәм Нурлат районы имам-мөхтәсибе Наил хәзрәт Әбелхановка тапшырылды.

■ dumrt.ru сайтыннан

# Яр Чаллыда яңа мәчет ачылды



16нчы октябрьдә Яр Чаллыда тантаналы рәвештә «Чаллы Яр» мәчете ачылды. Чарада Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин, Түбән Кама шәһәре имам-мөхтәсибе Салих хәзрәт Ибраһимов, хакимият органнары вәкилләре, кунаклар һәм шәһәр халкы катнашты.

Ачылыш Яр Чаллы шәһәренең «Җәмигъ» мәчете имамы Рамазан хәзрәт Идрисовның Изге Коръән аятьләрен укуы, аннан соң кунакларның Аллаһы Тәгалә йорты иминлеге өчен дога кылуы белән башланып китте. Аннан Татарстан мөселманнары башлыгы, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин дин кардәшләргә сәламләү сүзе белән мөрәҗәгать итте. Ул мәчет төзелешенә өлеш керткән шәһәр халкына рәхмәт белдерде һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәте исеменнән Рәхмәт хатлары тапшырды. Мәчет ачылышында башка мәртәбәле кунаклар да чыгыш ясады.

Барлык чыгышлардан соң мәчеттә беренче азан тавышлары яңгырады. Яр Чаллы мөселманнары, җомга намазын укырга дип, мәчеткә кереп китте – бередә алар, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинга ияреп, җомга намазын укыды.

Яңа мәчет берьюлы шәһәрнең Орловка бокрасы янында ышәүче кешеләр һәм юлчылар өчен хезмәт итәчәк, чөнки ул юл буенда урнашкан. «Чаллы Яр» мәчете физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрнең ихтыяҗларын да исәпкә алып төзелгән, бередә алар өчен аерым тәһарәтханә дә бар. Мәчетнең гомуми мәйданы 450 кв. м. тәшкил итә, ул берничә уку сыйныфын һәм чаралар үткәрү өчен аерым залны да үз эченә ала. Мәчет 200 дән артык кешене сыйдыра ала.

«Чаллы Яр» – шәһәрдәге high-tech стилендәге беренче мәчет. Бу объект башка мәчетләрдән гадәти булмаган архитектур корылышы белән аерылып тора – бинаның тышкы ягын һәм интерьерын бизәүдә high-tech стилендәге элементлар кулланылган.

Яр Чаллы мөхтәсибәтенә эш сәфәре кысаларында Камил хәзрәт Сәмигуллин шулай ук шәһәрнең «Зиннәт» гаилә үзәген дә күреп китте – бередә балаларны татар традицияләрендә тәрбияләүгә зур игътибар бирелә.

# «Яшь килен» проектының яңа сезоны башланды



22нче октябрьдә Казанда «Яшь килен» яшьләр проектының яңа сезоны башланып китте. Анда катнашырга Казанда яшәүчеләр генә түгел, ә Рәсәйнең башка районнары һәм төбәкләре дә теләк белдерде. Шуңа күрә дәресләр оффлайнда гына түгел, онлайн форматта да үткәреләчәк. Проектта Казаннан, Мәскәүдән, Уфадан, Пензадан, Петропавловскидан, Чистайдан, Әлмәттән һәм башка шәһәрләрдән утыздан артык гүзәл зат катнашачак.

Оффлайн курсларда катнашучыларны 10 очрашу – танышу, Татарстан мөфтиеннән мавыктыргыч, таныл белү лекциясе, психология һәм татар традицияләрен өйрәнү буенча дәресләр, аш-су остасыннан мастер-класс, кинозалга бару, тематик фотосессия һәм башкалар көтә. Оештыручылар һәм остазлар видеодәресләр, лекцияләр, тестлар һәм танышу, хитб (ярәшү, димләү), никах, никах килешүе, ир белән хатынның хокуклары һәм бурычлары, талак, гауրәт төшенчәсе, хатын-кызлар физиологиясе кагыйдәләре турында өстәмә белемнәр базасы кергән махсус телеграм-канал әзерләде.

Чарада онлайн катнашу исә үз эченә түбәндәгеләрне ала: реаль вакыт режимында дәресләр (Instagram ябык каналында эфир), видеодәресләр базасына керү, эш материалларын посылка белән җибәрү, танышу кагыйдәләре, хитб (ярәшү, димләү), никах, никах килешүе, ир белән хатынның хокуклары һәм бурычлары, талак, гаурәт төшенчәсе, хатын-кыз физиологиясе, шәхси куратор, тере аралашу турында телеграм-канал.

"Яшь килен" мөселман яшьләре арасында гаилә кыйммәтләрен ныгыту максатыннан гамәлгә ашырыла һәм шәригать һәм татар милли гореф-гадәтләр күзлегеннән чыгып никах темасының төрле мәсьәләләренә багышлана. Очрашулар һәм видеодәресләрдә булачак һәм хәзерге яшь киленнәргә милли традицияләр – бәби чәе, бишек җыры, кыз озату һ.б., никахның дини һәм хокукый яклары, хатын һәм ирнең бурычлары һәм хокуклары, мәһәр һәм никах килешүе, хатын-кыз һәм ир-ат психологиясе кебек мәсьәләләр турында сөйләнә. Моннан тыш, мөслимәләр милли ашлар әзерләргә, бала карарга, кунакларны каршыларга өйрәнә ала. Спикерлар булып психологлар, юристлар, табиблар, галимнәр чакырыла.

■ **dumrt.ru сайтыннан**

# Мөселман хатын-кызы

**«Аллаһы сезнең үзегездән сезгә хатыннар бар итте, ул хатыннарыгыздан исә сезнең өчен балалар һәм оныклар яратты һәм сезне ризыкландырды. Әллә алар [һаман да потлардан файда өмет итү кебек] ялганга ышаналар, Аллаһының исә [моның кадәр] нигъмәтен [күрә торып] инкяр итәләрме?»**

«Нәхел / Умарта кортлары», 16:72

Чыннан да, Аллаһы Тәгалә башта ир кешене – Адәмне балчыктан бар кылды. Аллаһы Тәгалә кешеләрне балчыктан күпме тели шуның кадәр ясый алыр иде, ләкин Ул Адәмнең парын аның кабыргасыннан бар итте. Әгәр хатын-кыз ир кешенең кабыргасыннан ясалмаган булса, ирләр хатын-кызларны шуның кадәр ярата алыр идеме, ә хатын-кыз ирне ир итәр идеме?

Ир – ир булып, хатын – хатын, бала – бала булып калсын өчен, фитрабызны саклар өчен Аллаһы Тәгалә динне бирде. Шушы тәрбия вакытында иң мөһим рольне уйнаучы зат – ул, мөгаен, хатын-кыздыр. Хатын-кыз гаиләнең үзәге, бәлки, нигезе булып торадыр, чөнки ул өйдәге тынычлыкны, чисталыкны булдыручы. Аның кулы аркылы өйдәге ризыклар үтә. Ул бала таба, аларны тәрбияли, бала аның аркылы дөньяны таный белә. Ир кешенең кәефе, пөхтәлеге, дәрәҗәсе хатын хезмәте белән булдырыла. Шулай итеп, хатын-кыз гаилә тормышында, ә димәк, җәмгыятьтә дә зур роль уйный, чөнки җәмгыять – ул гаилә, гаиләдән шул җәмгыятькә балалар чыга: алар нинди тәрбия алсалар, җәмгыять тә шундый булачак. Әгәр хатын-кыз үзенең шушы вазифаларын онытса яки үтәмәсә, нәрсә буласын күз алдына китерергә дә авыр, чөнки тормыш тәртибе югалачак. Хәер, күз алдына китерү авыр түгел: тирә-якка карау да җитә. Бүген без гаилә нигезләренең җимерел-гәнлеген, туганлык җепләре өзел-гәнлеген, ир белән хатынның урыннары алышынганын күрәбез. Монда күп нәрсәдән гаеп табарга, төрле катлам кешеләрен гаепләргә булыр иде, тик без бу проблеманың асылына карыйк әле. Шушы тормыш арбасында хатын-кызның урыны нинди икән?

Хатын-кызларга карата күп аятьләр һәм хәдисләр бар. Гәрчә Исламда хатын-кыз изелгән, чикләнгән дигән сүзләр ишетсәк тә, Ислам дине хатын-кызны бик югары бәяли. Хатын-кызга дәрәҗә биргән беренче дин – ул Ислам дине. Ислам дине таралу белән, динне тоткан хатын-кызлар да күбәя. Урамда, бүген кая гына барсаң да, яулык бәйләгән хатын-кызларны күрергә була, шөкер. Берәр җирлектә Ислам диненең таралганлыгын мәчетләрдән һәм яулыклы хатыннардан күрергә була. Яулык бәйләгән хатын-кыз зур корбан кылучы ул, чөнки безнең җирлектә яулык бәйләү – башкалардан аерылу булып тора. Ә бит беркемнең дә аерыласы килми. Шуның өстенә хатын-кызның үз матурлыгын да күрсәтәсе киләдер. Мөслимә хатын боларның барысын корбан итә. Ирләр җиңел генә хатын-кыз яулык бәйләргә тиеш дип кычкыра, ә үзләре көндәлек тормышта түбәтәй дә киеп йөри алмыйлар. Мәчеткә кергәндә кесәләреннән чыгарып кияләр дә, намаз беткәч, кире тыгып куялар. Ә хатын-кыз яулыгын бөтен җирдә бәйләп йөрергә мәҗбүр. Бу адымга кыю, ихлас кеше генә бара ала.

### Хатын-кызның төп бизәге – оялчанлык

Мөслимә хатын-кызның төп бизәге – ул оялчанлык. Хатын-кызның яулыгы-хиҗабы да аның бу сыйфатын ассызыклый. Шулай ук яулык хатын-кызның матурлыгын чит кеше күзеннән саклый. Зиннәтле әйбер бервакытта да аяк астында ятмый, еракка, пәрдә артына яшерелгән була. Яулык-хиҗапның максаты – шул. Яулык ул иреклек билгесе дә: диндә булмаган хатын-кыз матурлыгын каплап йөри алмый, ул аны бөтен кешегә күрсәтергә мәҗбүр. Ә мөслимә хатын-кыз теләгән кешесенә генә күрсәтә, димәк, ул иреклe һәм ихтыярлы. Тик бүген кайбер мөслимә кызлар да хиҗаптан йөрүгә карамастан матурлыкларын күрсәтергә тырышалар. Бу яулыкны артка бәйләп колакларын, муенны күрсәтүдә чагыла. Кайберләре исә урамга чыкканда ислемай куллана, бизәнә, ә бит бу дин тарафыннан тыелган. Шулай ук мөслимәләр арасында тырнак буяу да таралган. Буялган тырнакка су әләкми, димәк, тәһарәт тә дөрес булмый. Мөселман булмаган хатын-кызларга охшатып тырнак үстерүне дә күрергә була. Тырнак үстерү кыргыйлык билгесе булып тора. Шуңа да сөннәт буенча тырнак кисү, тәкләрне кыру каралган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тырнак астында шайтаннар оялый, дигән.

Кызганычка, кайчак мөслимәләрнең күлмәкләре дә шәригатькә туры килеп бетми. Артык сыланып торган күлмәкләр хатын-кызны яшерәсе урынга, киресенчә, аларның буй-сынын ачып сала.

Үзеңне иркен тоту оялчанлыкка каршы килә. Моңа егетләр белән иркен аралашу да керә. Кайвакыт мөслимә кызлар егетләр белән икәүдән-икәү кала. Әти-әниләре белән киңәшләшмичә кияүгә дә чыгарга мөмкиннәр.



### Хатын-кызның төп урыны – гаиләдә

Аллаһы Тәгалә безгә гаилә корырга әмер бирә:

**«Арагыздан буйдакларны, колларыгыздан һәм җарияләрегездән иман һәм тәкъвалык иясе булган кешеләрне никахлагыз...»**

«Нур», 24:32

Никахсыз мөнәсәбәтләрне динебездә күз алдына китереп тә булмый, бу зина була. Ир белән хатын никах укытып кына бергә тора алалар. Никахтан соң аларның тормышын гаилә кануннары көйли. Бүгенге көндә җәмгыятьтә гаиләләр-нең күп таркалуын күрәбез. Бу мөселман гаиләләрен дә урап узмый, алар арасында да аерылу күп. Димәк, дин гаиләне саклауга ярдәм итми булып чыга. Егетләр-кызлар динне гаилә тормышына күчерә алмыйлар.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Бергә яшәвегез өчен үзләрегездән сезнең өчен хатыннар яратуы һәм арагызда сөю [нәтиҗәсендә хасил булган бердәмлек] белән бер шәфкать [чарасы булган бала] бирүе дә – Аның билгеләреннән. Һичшиксез, монда уйлаганнар өчен [аңлатылып бетерә алмаслык дәрәҗәдә зур] билгеләр бар».**

«Рум», 30:21

Ир кеше өйләнеп, кайчагында тынычлык тапмый, аның тормышы тагын катлаулана, ул күбрәк борчыла башлый. Димәк, хатын-кыз аңа эзләгән тынычлыгын бирә алмый. Хатында матурлык, байлык, нәсел-нәсәп булса әйбәт, әлбәттә, тик тынычлык булмаса, гаиләдә боларның берсе дә кирәк түгел.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Хатын һәм балалар ир кешене харамга да кертергә мөмкин», – дип әйткән. Ничек итеп? Артык таләпләр куеп. Сәхабә хатын-кызлар ирләрен эшкә шундый сүзләр белән озатканнар: «Без хәерчелеккә түзәрбез, әмма тәмуг газабына түзә алмабыз, шуңа да хәләл мал алып кайтыгыз». Мөслимә хатын өчен мал беренче урында түгел, хәләллек беренче урында торырга тиеш.

Кайбер ирләр: «Хатыннарыбыз өйдә эшләми», – дип тә зарланалар. Имеш, алар эшләргә тиеш түгел. Чыннан да, гаиләне ир кеше тәэмин итәргә тиеш. Ләкин сәхабәләрнең хатыннары барысы да өйдәге эшләрне башкарган. Берьюлы Фатыйма радыяллаһу ганһә, әтисе Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килеп, авыр тормышына зарлана һәм ярдәмгә хезмәтче сорый. Расүлебез Гали радыяллаһу ганһене «Ник эшләтәсең», – дип ачуланмый, ә, зикер кылыгыз дип, киңәш бирә.

Бала тәрбиясе дә яхшы хатыннан тора, чөнки ир кешенең бала тәрбияләргә вакыты юк. Шуңа әниләр әтиләргә карата балада ихтирам булдыралар: «Әтиегез сезне ярата; әтиегездән рөхсәт сорагыз; әтиегезгә әйтәм; әтиегез кайта» сүзләре белән игелекле балалар тәрбияләнә.

Күргәнебезчә, хатын-кыз тормышта нинди зур роль уйный. Шуңа да иманлы, тәкъва мөслимә хатын-кыз җәмгыятьне тамырдан үзгәртеп кора ала. Һәрбер бөек ир артында бөек хатын тора, дигән сүз дә бар бит.

■ ТҖ МДНнең Дәгъват бүлеге

# Ибраһим галәйһиссәлам кыйссасы

*Дәвамы. Башы алдагы санда*

## Кем юмартрак?

Сынауны үткәннән соң, Исмәгыйль галәйһиссәлам атасыннан болай дип сорый:

– Ий атам минем! Безнең кайсыбыз юмартрак икән: синме-минме?

– Улым! Мин юмартрак, чөнки мин гомер буе көткән сау-сәламәт, үсеп җиткән, дөньяның бөтен байлыкларыннан да кадерлерәк булган бердәнбер газиз баламны Аллаһы юлында корбан итәргә әзер идем.

– Атам минем! Мин синнән юмартрак. Минем гомерем бер генә, син исә, мине корбан иткәннән соң, Раббыбыздан үзеңә тагын бала сорый ала идең.

Шулчак Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

– Мин сезнең икегездән дә юмартрак, чөнки берегезгә газиз бала, икенчегезгә гомер бүләк иттем.

Шулай итеп, барлык мөселманнарга Ибраһим галәйһиссәлам һәм Исмәгыйль галәйһиссәлам белән бәйле шушы бөек вакыйгаларны искә төшереп, корбан китерү Исламның бер вәҗиб гамәлләреннән санала. Корбан бәйрәме – җир шарының барлык почмакларында зурлап билгеләп үтелә торган мөселман бәйрәме ул. Корбан – Аллаһы безгә насыйп иткән зур гыйбадәт, Раббыбыз биргән чиксез нигъмәтләр өчен рәхмәтебезне белдереп, буйсынуыбызны күрсәтү, Аллаһыга мал-мөлкәтеңне корбан китереп, үзеңнең тугрылыгыңны һәм мәхәббәтеңне белдерү һәм дәлилләү мөмкинлеге.

## Ибраһим галәйһиссәламне байлык белән сынау

Аллаһы Тәгалә Ибраһим галәйһиссәламне Хәлил, ягъни дусты итеп игълан иткәч, фәрештәләр:

– Ий Раббыбыз! Син аны ничек итеп Үзеңнең дустың итеп таный аласың, аның йөрәге байлык һәм балаларына карата мәхәббәт белән тулы бит? – дип сорый. Раббыбыз:

– Аның калебендә Миннән башка бернәрсәгә дә сөю хисе юк. Теләсәгез, аны сынагыз, – дип әйтә.

Шунда бер фәрештә кеше кыяфәтенә кереп, Ибраһим галәйһиссәлам янына килә дә:

– Син зур байлыклар иясе, ә мин – мохтаҗ, – дип әйтә.

Ибраһим галәйһиссәлам болай дип җавап кайтара:

– Минем Раббыма мактаулар әйтсәң, сине үземнең милкемнән бүләклим.

– Суббухун Куддусун Раббуль-Мәләикәти вәр-рух.

– Байлыгымның яртысы – синеке! Раббыма тагын мактаулар ирештер – шушы көтүне тулысы белән сиңа бирәм.

Фәрештә тагын шушы тәсбихне кабатлагач, Ибраһим галәйһиссәлам тау башына менеп, барча көтүчеләренә болай дип җиткерә:

– Ий көтүчеләр! Мин сезне бөтен көтүләрегез белән шушы кешегә бүләк иттем, чөнки ул Аллаһы Тәгаләгә мактаулар әйтте.

Ибраһим галәйһиссәламнең шушы гамәленә һәм юмартлыгына исе киткән фәрештә:

– Мин сине сынарга дип килгән фәрештә һәм синең байлыкларыңа мохтаҗ түгел. Милкең үзеңдә калсын, – дип әйтә.

## Ибраһим галәйһиссәлам Кәгъбә төзи

Ибраһим галәйһиссәлам Әл-Харам җирендә хатынын һәм улын калдырып, туган ягына әйләнеп кайткач, ел саен гаиләсе янына килә торган була.

Ул хәзрәти Һаҗәр үлгән һәм Исмәгыйль галәйһиссәлам өйләнгән елны да килә. Әмма улын өйдә очрата алмый. Йортта аны улының яшь хатыны гына каршылый. Ул Исмәгыйль галәйһиссәламнең ауга киткәнен хәбәр итә. Ибраһим галәйһиссәлам:

– Ни хәлләрдә яшисез? – дип сорый. Килен:

– Без фәкыйрьлектә гомер кичерәбез, – дип җавап кайтара.

Моны ишеткәч пәйгамбәр:

– Ирең кайткач, миннән сәлам әйт һәм ишек тупсасын алыштырырга куш, – дип әйтә.

Ибраһим галәйһиссәлам өйгә кайткач, атасының исен сизеп ала һәм аның монда булганын аңлап, хатыныннан:

– Бүген безгә кем дә булса килдеме? – дип сорый. Ул:

– Әйе, бер карт кергән иде, хәлләрне сорашып, сиңа сәлам әйтергә һәм ишек тупсасын алыштырырга кушты, – дип җавап бирә.

Ибраһим галәйһиссәлам моны ишеткәч:

– Ул минем атам булган, ә ишегемнең тупсасы – син. Ул миңа синең белән аерылырга кушкан. Бүгеннән син үз гаиләңә кайта аласың, – дип әйтә.

Бу вакыйгаларда олы хикмәт бар. Пәйгамбәрләр беркайчан да нәфесләреннән чыгып сүз дә әйтмәгән, гамәл дә кылмаган. Бары тик Аллаһы кушуы буенча гына эш иткән. Мондый әмернең мәгънәсе дә шунда: сөекле расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Исмәгыйль галәйһиссәлам нәселеннән чыгарга тиеш булган, шуңа күрә аның хатыны да әлеге нәселнең анасы исеменә лаек булырга тиеш. Билгеле, холыксыз һәм көйсез хатын шушы олы дәрәҗәне күтәреп йөртерлек булмый.

Пәйгамбәрлек чылбыры Ибраһим галәйһиссәламнең ике улы – Исхак һәм Исмәгыйль галәйһимуссәламгә барып тоташа. Хәзрәти Сара һәм Ибраһим галәйһиссәламнең улы Исхак галәйһиссәламнән Исраил угыллары кавеме барлыкка килә. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм генә хәзрәти Һаҗәрдән туган Исмәгыйль галәйһиссәлам нәселеннән чыга.

Күпмедер вакыт узгач, Исмәгыйль галәйһиссәлам Җөрхем кавеменнән үзенә икенче хатын ала. Ул өйдә берүзе калган мәлдә Ибраһим галәйһиссәлам улының хәлен белергә дип килә. Килененең хәл-әхвәлен сорагач, ул:

– Исмәгыйль безгә ризык эзләп, ауга китте, – дип җавап кайтара. Ибраһим галәйһиссәлам:

– Ни хәлләрегез бар? – дип сорый. Килен:

– Аллаһыга шөкер! Без бәхетле һәм имин яшибез, – дип әйтә. Ибраһим галәйһиссәлам:


– Нәрсә ашыйсыз һәм эчәсез? – дип сорый. Килен:

– Ит ашап, су эчәбез, – дип әйтә.

Ибраһим галәйһиссәлам моны ишеткәч:

– Ий, Раббым, аларның итләрен һәм суларын бәрәкәт белән бүләклә, – дип дога кыла.

Пәйгамбәрнең бу догасы белән Аллаһы Тәгалә алар яшәгән бөтен җирлеккә бәрәкәт иңдерә – монда һәрчак җитәрлек ит һәм су була.



Ибраһим галәйһиссәлам үз килененең күркәм холкын ошата һәм аңа:

– Ирең өйгә кайткач, аңа миннән сәлам җиткер һәм ишек тупсасын яхшы карарга куш, – дип әйтә.

Бу вакыйга турында хатын ире Исмәгыйль галәйһиссәламгә сөйли. Ул:

– Бу минем атам иде. Ә син – ишегемнең тупсасы. Ул миңа сине кайгыртып һәм яратып яшәргә кушкан. Син элек тә күңелемә газиз идең, хәзер тагын да сөеклерәк булдың, – дип әйтә.

Күпмедер вакыттан соң Аллаһы теләге белән Ибраһим галәйһиссәлам кабат Әл-Харамга килә. Монда аңа Бәйтуллаһны яңадан төзергә кирәк була. Исмәгыйль галәйһиссәлам атасын еракта ук күреп алып, янына чабып килә, кулларын үбә, алар кочаклаша.

– Ий улым! Раббыбыз миңа бөек гамәл кылырга кушты. Ярдәм итәрсеңме? – дип Ибраһим галәйһиссәлам улына сүз ката.

Ул вакытта Кәгъбәдән бары кечкенә тау гына калган була. Силләр һәм су басулар аның нигезен генә калдыра. Ибраһим галәйһиссәлам белән Исмәгыйль галәйһиссәлам аны чистартып, диварларын күтәрә башлыйлар. Исмәгыйль галәйһиссәлам ташлар ташып тора, ә атасы аларны тезеп сала.

Кәгъбә шактый күтәрелгәч, Исмәгыйль галәйһиссәлам бүген «Ибраһим мәкаме» дип йөртелә торган бер таш китерә. Ибраһим галәйһиссәлам, буе җитмәгәч, аңа басып диварларны төзүне дәвам итә, шуңа бу ташта аның аяк эзләре уелып кала. Аллаһы Йорты төзелеп беткәч, ата белән ул, шушы олы хезмәтне кабул итүен сорап, Раббыбызга дога кыла:

**«Вакытында Ибраһим белән Исмәгыйль [галәйһимуссәлам] Бәйттән [Адәм [галәйһиссәламнән соң] калган нигезләрне [табып, диварларын] күтәрделәр [һәм, шул ук вакытта, болай дияләр иде]: «Ий Раббыбыз! [Бу хезмәтебезне] Бездән кабул ит, һичшиксез, Син – [һәрнәрсәне] Ишетүче, [һәрнәрсәне] Белүче!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:127

Соңыннан Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһы кушканча Кубайс тавына менеп (кайбер риваятьләрдә Ибраһим мәкаме ташына басып дип әйтелә) кешеләргә хаҗ кылу кирәклеге турында хәбәр итә:

– Ий кешеләр! Раббыбыз безгә Аның Йортын әйләнеп тәваф кылырга куша. Ий, кешеләр, бу әмерне үтәгез!

Раббыбыз Аллаһы һәрбарчабызга да шушы изге җирләрдә хаҗ кылырга һәм Аның Йортына маңгайбитләребез һәм йөрәкләребез белән кагылып китәргә язсын иде!

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин,**
**Татарстан Республикасы мөфтие**

# Пәйгамбәр күрсәтмәләре — безгә маяклы юл

Рабигыль-әүвәл ае башланды. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм рабигыль-әүвәл аенда туган, рабигыль-әүвәл аенда дөньядан үткән. Без бу айда аның тормышын, сыйфатларын өйрәнергә, аны күбрәк искә алырга, аңа охшарга тырышырга тиеш. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең күркәм сыйфатларының берсе – күркәм холкы, күркәм әхлагы. Аллаһы Раббыбыз да аңа: «Синең әхлагың төзек булмаса, синең күңелең йомшак булмаса, сиңа иярүчеләр дә шушы хәтле күп булмас иде», – дип әйткән. Ислам динебезнең нигезе булып тәүхид – бер Аллаһыга гына ышану торса, аның икенче мөһим өлеше – гүзәл әхлак, күркәм холык. Аллаһының безгә боерган фарызлары, тыйган харамнары бүген безнең әхлагыбызны төзәтергә ярдәм итә. Әгәр бер кеше намаз укып, ураза тотып, аның холкы яман булса, аның теленнән дә, кулыннан да башкалар зыян күрсәләр, бу вакытта аның шушы ямьсез холкы, начар гадәтләре кылган фарыз гамәлләрен юкка чыгара, аларның әҗерен бетерә. Димәк, бу кеше намаз укымый, тик хәрәкәтен генә ясый, теленнән дә, кулыннан да, сүзеннән дә тирә-юньдәге кешеләргә тынгылык юк. Димәк, аның намазы «өлгереп», «пешеп» җитмәгән. Кеше намаз укый, ураза тота икән, ул – гүзәл әхлак иясе дә булырга, үзен-үзе тыя белергә дә тиеш. Шушы вакытта гына аның үтәгән фарыз гамәлләре кабул булачак, дип әйтелә хәдисләрдә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер хәдисендә болай дип әйтелә: «Бер кеше гүзәл, күркәм холыкка ия булса, аның шушы гүзәл холкы нәфел уразалары, нәфел намазы савабын алу дәрәҗәсенә күтәрелер».

Пәйгамбәребезнең гүзәл холык, күркәм әхлак турында тагын бер хәдисе бар: «Шәригатебезгә һәм акылыбызга муафыйк булмаган, начар, фәхеш, оятсыз булган сүзләрне кычкырып сөйләмәгез, аны кат-кат әйтмәгез».

Хәдиснең беренче өлешендә Пәйгамбәребез телебезне бозык сүзләр әйтүдән сакларга куша. Безнең нәфис әдәбиятыбыз, матур сәнгатебез дә әхлакны төзәтү юлында эшләргә тиеш.

Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте:

**«Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә бер кавемдә булган нәрсәне, алар үзләре яхшы гамәлләрен явызлыкларга алмаштырганчы үзгәртми, ягъни халыктан күркәм хәлнең китүенә халык үзе сәбәпче».**

«Әр-Рагъд / Күк күкрәү», 13:11



Без бүген татар халкын, татар милләтен күтәрергә теләсәк, иң беренче чиратта әхлакны төзәтергә кирәк. Гүзәл әхлаклы халыкны беркем дә җиңә алмый. Бозык әхлаклы халыкка исә бернинди дошман да кирәк түгел, ул үз бозыклыгы белән үзен-үзе юкка чыгара.

Әхлак төзәтүнең иң беренче адымында без балаларыбызны Аллаһыны танырга, Аллаһыны хөрмәт итәргә өйрәтик. Аллаһының безгә кушкан иң зур фарызы – гыйлем. Гыйлемгә мәхәббәт уятырга кирәк. Гыйлем нәрсә ул? Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу сорауга: «Гамәл һәм әдәп», – дип җавап бирә. Димәк, берәү гамәлен үтәп, аның әдәбе булмаса, ул – надан. Гыйлемле кеше гамәлне, фарыз гамәлләрен үтәргә, харамнан тыелырга тиеш. Һәм аның шушы ук вакытта әдәпле, күркәм кеше булып калуы шарт. Аңардан нур бөркелеп торсын. Ул фарыз гамәлләрне кеше күрсен өчен генә, йә булмаса, кемдер кушкан өчен генә үтәмәсен, үзе тырышып, гүзәл әхлакка килсен. Шулай булмаса, ул үз эшен җиренә җиткерми, дигән сүз. «Хикмәт нәрсә ул?» – дигән сорауга пәйгамбәребез Мөхәммәд: «Гыйлем белән гамәлнең туры килүе ул», – дип җавап кайтарган. Берәү галимлеккә ирешә, әмма ялкау була. Намазларын укымый, ураза тотмый. Үзе динен дә яхшы белә: «Мин динле, шәригатьне бик яхшы беләм», – дип, мактанып та йөри әле. Әмма үзе харамнан тыелмый, фарыз гамәлләрне үтәми. Димәк, моның гыйлемлегеннән үзенә дә, халыкка да бер файда да юк. Берәү тырыша, гыйбадәт, гамәл кыла, ураза тота, намаз укый – гыйлеме юк. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Диннең афәте өчтер: аның беренчесе – бозык имамдыр, икенчесе – залим түрәдер, өченчесе – үзе надан булып та, дин өчен тырышлык күрсәтүче кешедер», – дип әйткән.

Без балаларыбызда гүзәл әхлак тәрбияләгәндә, аларның үз көчләренә үзләре ышану рухын күңелләренә сеңдерергә тиеш. Күркәм әхлак тәрбияләүнең бер юнәлеше – вазифаңны, җәмгыятьтә үз урыныңны белү. Сиңа бер эш йөкләтелгән икән, аны намус белән башкарырга тиешсең.

Тәрбияләүгә кечкенәдән тотынырга кирәк. Анда да бөтен игътибарны әхлак төзеклегенә, әхлак төзәтүгә юнәлтик. Аллаһыны тану, Аны хөрмәт итү, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне пәйгамбәр дип тану, аннан үрнәк алу, аның тормышын өйрәнү һәм Аллаһы Тәгалә кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәү гүзәл әхлакка китерер. Әхлак нигезсез була алмый. Ул әхлак Аллаһыны танудан башланырга тиеш. Бу дөньяда мәңге үзгәрми торган фәкать бер Аллаһы Тәгалә, Аның кануннары бар. Шуңа күрә без Аллаһы Тәгалә кушкан әхлак белән, Ул кушканча яшәргә тиеш. Аллаһы Тәгалә тыйганнардан тыелырга тиешбез.

Без, иманыбызны ныгытып, җаннарыбызны сафландырып, гүзәл әхлак белән яшәргә тиешбез. Гыйлемнең нигезен – Аллаһыны тану гыйлемен өйрәник. Аны «тәүхид гыйлеме» диләр. Аллаһының берлегенә инану гыйлеме, Аллаһыны тану гыйлеме. Аллаһыны танысак, Аны инкяр итмәсәк, харам дигән әйберләрдән тыелсак, дөрес әхлакка ирешербез.

Кешедә холык ике төрле була. Бала туганда ук шатлана, борчыла, кайгыра, көлә, матурлык өчен сөенә, начар әйберне күрсә – көенә. Бу – холыкның тумыштан булган, үзгәрми торган сыйфатлары. Бу сыйфатлар кеше картайганчы дәвам итә, үзгәрми. Кешенең берсе намаз укый, ураза тота, Аллаһы Тәгалә кушканча яши. Әмма холыкта икенче төрле як та бар. Кеше отышлы уеннар уйный, харам ризыклар ашый: менә монысы – холыкның үзгәрә торган яклары. Без холыктагы үзгәрә торган якны тәрбияләргә тиеш. Пәйгамбәрләр дә шуның өчен җибәрелгәннәр.

Бүген без рабигыль-әүвәл ае, Мәүлид ае, дибез икән, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә дөрес юлны өйрәтер өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән пәйгамбәр икән, без аның эшен дәвам итеп, кешеләрнең холкын яхшы якка үзгәртү өчен эшләргә тиешбез. Бөтенебез дә. Әгәр шушы эшне эшли алмасак, безнең җәмгыятебез бетәргә мөмкин.

Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте:

**«Тәхкыйк, сездән әүвәл килеп золым кылган кавемне Без һәлак иттек, моннан гыйбрәт алыгыз! Расүлләре аларга ачык могҗизалар, вә ислам диненең гадел хөкемнәре белән килделәр, шулай да иман китермәделәр. Шуның кеби гөнаһка чумган кешеләрне җәза кылачакбыз».**

«Юныс», 10:13

Кабаттан, Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте:

**«Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә бер кавемдә булган нәрсәне, алар үзләре яхшы гамәлләрен явызлыкларга алмаштырганчы үзгәртми, ягъни халыктан күркәм хәлнең китүенә халык үзе сәбәпче».**

«Әр-Рагъд / Күк күкрәү», 13:11

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер хәдисендә Кыямәт көнендә Аллаһының рәхмәтенә ирешәчәк 7 төрле кеше күрсәтелә. Шуның беренчесе – гадел җитәкче. Икенчесе – мәчеттә укылган намаздан яңадан анда керү теләге белән чыккан кеше. Өченчесе – гыйбадәт кылучы егет. Дүртенчесе – Ахирәт, Аллаһы ризалыгы өчен дуслашкан кешеләр. Бишенчесе – садаканы яшерен бирүче кеше. Алтынчысы – аулакта бер Аллаһының ризалыгын өмет итеп кенә намаз укып, күзләреннән яшь чыгарып гыйбадәт кылучы. Соңгысы – берәү бозык юлга чакырганда, Аллаһыдан куркып, үзен шушы бозыклыктан тыеп кала алган кеше.

Аллаһы Раббыбыз барчабызга да шушы сәгадәтне бирсен иде. Әгәр безнең оныкларыбыз шушы сәгадәткә ирешсәләр, әлбәттә, милләтебез дә аек, көчле булыр, нык булыр, һәм Татарстаныбыз да шушы гүзәл холыклы кешеләр белән матур тормышта яшәр.

■ ***Җәлил хәзрәт Фазлыев,***
**Татарстанның баш казые**

# Пәйгамбәребез Мөхәммәд исеменнән соң әйтелгән салаватның мәгънәсе нинди?

**Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм исеменнән соң кулланыла торган салават турында төгәл генә мәгълүмат таба алмыйм. «Салләллаһу галәйһи вә сәлләм» һәм «галәйһис-саләтү вәссәлләм» гыйбарәләре арасында аерма бармы?**



**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм!

Беренчедән, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтү – иң мөһим сөннәт һәм зур әҗерләр вәгъдә ителгән изге эшләрнең берсе.

Габдулла бине Мәсгудтан тапшырыла, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кыямәт көнендә миңа иң якын булган кеше – миңа күпләп салават әйткән кеше булыр», – дип әйткән (Тирмизи, № 484, Ибне Хиббән, № 911).

Икенчедән, салаватның мәгънәсенә килгәндә, имам Әс-Сануси рахимәһуллаһи аны болай аңлата:

«Аллаһыга карата «әс-саләт» сүзе өстәмә хөрмәт һәм изгелекләр белән бүләкләүне аңлата. Ә «әс-сәләм» сүзе Аллаһыдан аңа (Пәйгамбәребезгә) өстәмә иминлек, изге сәламләү һәм олуглау дигәнне аңлата» («Шәрх әс-Сугра»).

Бу фикерне ачыклап, шәех Ибраһим Әд-Дусуки рахимәһуллаһи болай дип әйтә: «әс-саләт» сүзе мәхлүкълар өчен (мәсәлән, кешеләр, фәрештәләр) дога ролен үти, ягъни Аллаһыга дога белән мөрәҗәгать итеп, кеше Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә хөрмәт, мәрхәмәт һәм аның дәрәҗәсен күтәрүне сорый.

Аллаһыга карата «әс-саләт» сүзе Пәйгамбәребезне өстәмә олылау һәм аңа өстәмә мәрхәмәт күрсәтү дигәнне аңлата. Ни өчен өстәмә? Чөнки Аллаһы Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне болай да олуглаган: ул аны кешеләр арасында иң күркәме итеп сайлаган һәм башка пәйгамбәрләрнең юлбашчысы итеп билгеләгән. Шуңа күрә Аллаһыдан салават – Пәйгамбәребезнең болай да югары булган дәрәҗәсен тагын арттыру һәм аның тагын да зуррак изгелекләр белән бүләкләү дигәнне аңлата.

Ә без салаватны әйткәндә, бу изгелекләрне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өчен Аллаһыдан сорыйбыз булып чыга.

«Әс-сәләм» сүзе, югарыда әйтелгәнчә, өстәмә иминлек, изге сәламләү һәм олуглау дигәнне аңлата. «Өстәмә иминлек» дигәндә Аллаһының Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне үзе өчен, өммәте өчен куркулардан азат итүен аңларга кирәк. Бу урында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе өчен куркырга ниндидер нигез булган дип уйлау дөрес булмас, кеше Аллаһыга никадәр якын булса, шулкадәр Аллаһыдан курка (әд-Дусуки).

Димәк, «салләллаһу галәйһи вә сәлләм» гыйбарәсенең мәгънәсен түбәндәгечә аңлау тиешле: «Йә Раббыбыз, без Синнән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә тагын да күбрәк хөрмәт, изгелек бирүеңне, аны борчылырга мәҗбүр итә торган бар нәрсәдән саклавыңны; аның дәрәҗәсен күтәрүеңне һәм аны җәннәт әһелләренең иң күркәм сәламе белән сәламләвеңне телибез».

«Салләллаһу галәйһи вә сәлләм» гыйбарәсен «аңа Аллаһының рәхмәте һәм сәламе булсын» дип аңлау дөрес, ул бары гыйбарәгә салынган барлык мәгънәләрне генә биреп бетерми.

Өченчедән, сез «салләллаһу галәйһи вә сәлләм» һәм «галәйһис-саләтү вәссәлләм» гыйбарәләре арасында аерма бармы, дип сорадыгыз. Алар арасында аерма юк дияргә була. Беренче гыйбарәдә без Аллаһының исемен әйтәбез, ә икенчесендә исемен әйтмичә, Аны күз алдында тотабыз.

Ә Аллаһы – яхшырак Белүче.

# Намаз вакытында телефон шалтыраса

**Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Кайвакыт, игътибарсызлык аркасында, намаз укыр алдыннан телефонны сүндерергә онытабыз. Намаз укый башлагач, телефон шалтыраса, аны сүндерергә ярыймы?**

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм! Намаз укыган вакытта телефонны сүндерергә бүленү намазны бозарга мөмкин. Шәригать бу гамәлне гамәл кәсир рәтенә кертеп карый. Гамәл кәсир – ул намаз эчендә намазны бозу ихтималы булган хәрәкәтләр саны. Гамәл кәсир, димәк, намазны боза.

Гамәл кәсирне нинди критерийлардан чыгып билгеләргә?

Хәнәфи мәзһәбенең билгеле «Фәтава Кадыхан» хезмәтендә кайбер имамнар болай дип әйткәннәр: «Әгәр намазын артык хәрәкәтләр ясап укыган кеше янында басып торучы берәүнең, бу кешенең намаз укымавына һич шиге булмаса (ягъни аның ясаган хәрәкәтләре намаз укыган кешенекенә бөтенләй охшамаган), бу хәрәкәт гамәл кәсир санала. Әгәр күзәтүче намазда артык хәрәкәтләр ясаган кеше турында намаздамы соң бу, юкмы дип, шиге туса, бу хәрәкәт гамәл кәсиргә керми. Имам Әл-Хәлвани рахимәһуллаһи болай дип әйткән: «Бу бәя Әбү Хәнифә мәзһәбенә бик якын, чөнки ул моның кебек сораулар туган вакытта күләмне билгеләмәгән (бу очракта хәрәкәт санын), ә хөкемне бу ситуациядә калган кешенең үзенә калдырган». (Шушы ук фикерләр «Әл-Мохит әл-Борхани» һәм «Радд әл-Мохтар» хезмәтләрендә дә искә алына).

«Хашия Тахтави» әсәрендә гамәл кәсир төшенчәсенә тагын да ачыграк билгеләмә бирелә:

«(Бу) намазның бер рөкенендә (рөкүгъ, кыям һ.б.) бер-бер артлы башкарылган артык өч хәрәкәт».

Моннан чыгып, без түбәндәге нәтиҗәне ясый алабыз:

1. Телефонны сүндерү намазны боза, әгәр ул гамәл кәсир категориясенә караса;
2. Гамәл кәсирнең иң дөрес критерие – бер рөкендә башкарылган өч артык хәрәкәт.
3. Намаз укучы кеше бер кулы белән генә телефонын сүндерсә, ягъни телефонны сүндергәндә өч хәрәкәт ясамаса, бу хәрәкәт гамәл кәсиргә керми, һәм намаз бозылмый.

# Таң беленгәч намаз уку

**Сорау: Әссәләмү галәйкүм! Сәхәр тәмам булганнан соң, мәчет намазы уку ярыймы?**


**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм! Сәхәр тәмам булган вакыттан алып мәчет намазын уку мәкруһ, чөнки ул намаз нәфел намаз санала. Имам Шурунбуләли рахмәтуллаһи галәйһи «Нур әл-Идах» хезмәтендә:

«Таң беленгәннән соң нәфел намазлар уку мәкруһ, таң беленгәннән соң бары иртәнге намазның сөннәтен генә укырга ярый», – дип яза.

Ә Аллаһы – яхшырак Белүче.

■ **Булат хәзрәт Мөбарәков,**
**ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе**

# Мөфти Халыкара белем бирү симпозиумында




22 нче октябрьдә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин «Хәзерге Рәсәйнең фәнни-мәгариф киңлегендә традицион диннәр теологиясе» Халыкара симпозиумының пленар утырышында чыгыш ясады. Халыкара симпозиум Казанда 22-23 нче октябрь көннәрендә «Фәнни-мәгариф киңлегендә теология: бурычлар һәм карарлар» IV Бөтенрәсәй фәнни конференциясе кысаларында уза.

Халыкара фәнни-гамәли конференцияне Теология фәнни-белем бирү ассоциациясе (НОТА) Рәсәй ислам институты белән берлектә үткәрә. Конференцияне оештыруда шулай ук ТР мөселманнары Диния нәзарәте, Ислам мәдәниятенә, фәненә һәм мәгарифенә ярдәм фонды, Рус Православие Чиркәвенең Казан епархиясе, Казан православие Руханилар семинариясе катнаша.

Халыкара симпозиум катнаш форматта: бөтен Рәсәйдән 200 дән артык фәнни-белем бирү һәм фәнни-эксперт җәмәгатьчелеге белгечләре (фәнни-педагогик хезмәткәрләр, аспирантлар, докторантлар); традицион диннәр, дини уку йортлары вәкилләре, хакимият органнары вәкилләре катнашында уза. Халыкара симпозиум теологиягә гуманитар белем бирү тармагы буларак карау, аның башка фәннәр белән бәйләнышына уңай караш формалаштыруга; динара бәйләнешне ныгыту һәм теологик белем бирүне үстерүгә; дәүләт һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгытуга; рухи-әхлакый тәрбия эшендә катнашучы субъектларның тырышлыгын берләштерүгә юнәлтелгән.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Халыкара симпозиумда катнашучыларны сәламләп, республикада квалификацияле теологлар һәм дини кадрларның үз дини-илаһият һәм милли традицияләребезне исәпкә алып әзерләнергә тиешлеген аңлауның көннән-көн ныгый баруын билгеләп үтте. Әлеге традицияләр Рәсәй җирлегендә күпдинле җәмгыять шартларында барлыкка килгән. Мөфти хәзрәт, игътибарны сыйфатлы заманча теологик белем бирү системасын үстерү мәсьәләсенә юнәлтеп, бу мәсьәләнең дәүләт дәрәҗәсендә куелырга тиешлеген ассызыклады. «Чөнки теология әхлакый кыйммәт-ләрне үстерү һәм тәрбияви миссияләрен үтәргә, динара бәйләнышларны ныгытуга ярдәм итәргә тиеш», – диде ул.

Шул ук вакытта җәмгыятьтә гражданнар арасындагы һәм динара татулыкны саклау шулай ук дини белем бирү системасының үсеш дәрәҗәсенә дә бәйле, чөнки дин мәсьәләләрендә наданлык җимергеч нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. «Мәсәлән, табиб хатасы авыруның сәламәтлегенә зыян китерсә, гыйлемсез имам – кешенең рухына зарар салырга мөмкин, ул чакта кеше мәңгелек дөньяда үз ялгышлары өчен түләргә тиеш булачак", – диде мөфти.

Камил хәзрәт үз чыгышында ил һәм республика җитәкчелегенә – Рәсәй Президенты Владимир Владимирович Путинга һәм Татарстан Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнехановка Рәсәйдә һәм Татарстан Республикасында ислам мәгарифен үстерү мәсьәләләрендә һәрьяклап ярдәм күрсәткәннәре өчен рәхмәт белдерде. «Аларның ярдәме белән, бүгенге көндә Татарстанда күпбаскычлы мөселман белем бирү системасы төзелде. Мәчет каршындагы курслар, мәдрәсәләр, югары уку йортлары һәм Болгар ислам академиясе башлангычтан алып докторлык дәрәҗәсенә кадәр ислам турында белемнәр алырга һәм үз өлкәсен бик яхшы белгән белгечләр тәрбияләргә, хәтта аларны башка төбәкләргә һәм илләргә динебезнең асыл кыйммәтләрен тарату максатыннан җибәрергә мөмкинлек бирә», – дип тәмамлады чыгышын мөфти.

Халыкара конференция Рәсәйдә теология белеме һәм конфессияара диалогны үстерүгә кагылышлы мөһим мәсьәләләрне карый. Көн тәртибенә традицион диннәр теологиясе һәм белем бирү җирлегендә фәнни-педагогик һәм дини берләшмәләрнең үзара хезмәттәшлеге; илнең рухи иминлеге; рухи кыйммәтләрне, динара татулык идеяләрен, Рәсәй халыкларының мәдәни традицияләренә толерант мөнәсәбәт булдыру; дини берләшмәләрнең Рәсәй җәмгыяте тормышына уңай өлеш кертүе аркылы дәүләти-дини мөнәсәбәтләрне ныгыту; хәзерге плюралистик җәмгыятьтә гармонияле милләтара һәм динара мөнәсәбәтләрне саклау факторы буларак – теология кебек һ.б. мәсьәләләр чыгарыла.

Төштән соң Халыкара симпозиумда катнашучылар секцияләргә бүленеп эшләде. Аерым алганда, катнашучылар Болгар ислам академиясендә магистрлар һәм докторлар әзерләү системасы, Татарстанда дини һәм дөньяви уку йортларының хезмәттәшлек итүе, башлангыч баскычта белгечләрне дини белем бирү стандартларын кулланып әзерләү, дини мәгариф оешмаларында, дистанцион белем бирү технологияләрен кулланып, укыту эшчәнлеген алып бару, фәнни-тикшеренү эшчәнлеген оештыру һ. б. мәсьәләләрне карады. Ә шул ук вакытта Казан православие Руханилар семинариясендә «Татарстан Республикасының рухи һәм дөньяви уку йортлары мисалында христиан һәм Ислам теологиясенең үзара хезмәттәшлеге» дип аталган түгәрәк өстәл утырышы узды.

23 нче октябрьдә – «Хәзерге Рәсәйнең фәнни-мәгариф киңлегендә традицион диннәр теологиясе» Халыкара симпозиумы үз эшен Рәсәй ислам институтында дәвам итте. Көн «Фәнни-мәгариф киңлегендә теология: бурычлар һәм карарлар» IV Бөтенрәсәй фәнни конференциясе эше һәм катнашучыларга сертификатлар тапшыру белән тәмамланды.

Алга таба Халыкара симпозиум нәтиҗәләре буенча резолюция кабул итү, тәкъдимнәр эшләү, фәнни мәкаләләр җыентыгын бастыруга әзерлек алып бару көтелә.

■ **dumrt.ru сайтыннан**

# Изге Китабыбызны өйрәнәбез

### Фәрештә килеп: «Укы» дип әмер бирде

Коръәннең беренче аятьләрен Раббыбыз Пәйгамбәребезгә Нур тавының Хира тау куышлыгында булганда индерә. Җәбраил галәйһиссәлам «Әл-Галәк» сүрәсенең беренче биш аятен «Икра!», ягъни «Укы!» дигән әмер белән башлый.

Пәйгамбәребезгә беренче вәхи 40 яшендә килә. Бу 610 нчы елның Рамазан ае, ягъни ураза вакыты, дүшәмбе көн була. Әлеге вакытта иңә башлаган вәхи Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу дөньядан киткәнче дәвам итә. Коръән иңә башлаган кич «Ләйләтүл Кадр» дип йөртелә. Мөселманнар бу төнне догада, гыйбадәттә булып үткәрә.

### Безнең Китабыбызның күркәм исемнәре бар

Коръән – бөек Китап, аны уку Аллаһыга гыйбадәт кылу булып санала.

Коръән – Әл-Фуркан – яхшыны яманнан, хакыйкатьне ялганнан аера.

Коръән –Ән-Нур – кешелек өчен Кыямәт көненә кадәр юл күрсәтеп тора.

Коръән – Әш-Шифа – безне калеб авыруларыннан дәвалый.

Коръән – Әл-Һидая. Ул хәтта иң авыр вакытларда да туры юлдан читкә тайпылырга бирми.

Коръән – Әз-Зикер. Ул кешегә үзен һәм Раббысын онытырмый.

Коръән – Әл-Кәлам, Аллаһының сүзе.

### Аятьләр бер-бер артлы иңгәннәр

**«Һичшиксез, бу Коръән иң туры булган юлга илтә һәм изге гамәлләр кылган мөэминнәрне алар өчен [җәннәт кебек] зур бер әҗер булуы белән сөендерә».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:9

Коръән сүрәләрдән, ә сүрәләр аятьләрдән тора. Изге Китабыбызда барлыгы 114 сүрә һәм 6236 аять бар.

Кайбер аятьләр берничә хәрефтән генә тора, ә кайберләре бер биткә җитә.

Коръән бер тапкыр гына түгел, ә аерым-аерым булып, өлешләп иңгән. Еш кына кайбер аятьләр берәр төрле вакыйгадан соң иңеп, булган хәлләргә аңлатма биргән.

Аятьләрнең иңү вакыты 23 елга сузылган. Моның хикмәте бар. Бу – кешеләр Коръәнне яхшырак аңласын, аз-азлап тормыш-көнкүрешкә кертеп җибәрсен өчен шулай булган. Үләннәр дә көнләп үсеп, йорт та һәрбер салынган кирпеч белән күтәрелгән кебек, Коръән дә кешеләр яхшылап аңласын өчен, аз-азлап иңгән.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әлеге 23 елның 13ен Мәккәдә, ә 10ын Мәдинәдә үткәргән. Шуның өчен Мәккә шәһәрендә иңгән аятьләрне «Мәккә аятьләре», ә Мәдинәдә иңгәннәрен «Мәдинә аятьләре» дип атыйлар. «Мәккә аятьләре»ндә, күпчелектә, иман нигезләре, тәрбия асылы, үлгәннән соң терелү хакында әйтелә. «Мәдинә аятьләре»ндә гаилә һәм җәмгыять темалары күтәрелә.

Ә сүрәләргә килгәндә, алар да аятьләр кебек, кайвакыт озын, ә кайчак кыска булалар. Мәсәлән, «Әл-Бәкара / Сыер» сүрәсе 20 биттән артып киткән. Ул Изге Китабыбызның иң озын сүрәсе. Әмма берничә юлдан гына торган сүрәләр дә бар. Шуларның иң кыскасы «Әл-Кәүсәр / Муллык» сүрәсе.



■ **Сәхифәне Айсылу Юлдашева әзерләде**


## «Хозур» нәшрият йорты «Ислам. 75 дәрес» китабын нәшер итте




Аллаһыга шөкер, укучыларыбызның күпсанлы соравы буенча, ТҖ мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты «Ислам в 75 уроках» китабының татарча вариантын – «Ислам. 75 дәрес» басмасын тәкъдим итте.

Әлеге китап Ислам диненә бәйле һәм һәрбер мөселманга кирәк булган белемнәрне (гакыйдә, гыйбадәт, әхлак, гомуми мәдәният, тәҗвид, пәйгам-бәрләр тарихы һәм сира) үз эченә ала. Яңа гына Ислам динен кабул итүчеләр өчен бу китап Шәригать хөкемнәре, пәйгамбәрләр тарихы, Ислам диненә бәйле әдәп-әхлак, шулай ук Аллаһы Тәгаләнең боерыклары һәм тыюлары белән таныштыра торган беренче белешмәлек; ә дини гыйлемнәре булган мөселманнар өчен тормыш-көнкүрешләрендә, мөгаллимлек эшчәнлек-ләрендә практик кулланма булачак. Китап киң катлам укучыларга аңлаешлы җиңел телдә язылган, анда бирелгән мәгълүмат кыска һәм төгәл.

«Ислам. 75 дәрес» китабын «Хозур» нәшрият йорты кибетләрендә сатып алырга һәм җир йөзенең теләсә кайсы почмагыннан заказ бирергә мөмкин.

**Кибет:** Казан шәһ., Тукай ур., 36нчы йорт. Тел.: +7 960 072-74-63;

**Склад:** Казан шәһ., Газовая ур., 14нче йорт. Тел.: +7 (966) 250-00-09;

**Интернет-кибет:** huzurshop.ru (http://huzurshop.ru/).

# Пәйгамбәребезнең дөньяга килү кыйссасы




…Сәедебез пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең атасы Габдулла, аның атасы Габделмотталиб иде. Габделмотталибның дөрес исеме – Шибәтүл-хәмед, чөнки Габделмотталибның туган вакытында башында ак төкләре бар иде. Габделмотталибның атасы Һашим, чын исеме Гамру, аның атасы Габдемәнәф, чын исеме Могыйра, аның атасы Кусай, чын исеме Мөҗәммигъ, аның атасы Киләб, чын исеме Хәким, Мөрра Кәгъб улы, Кәгъб Ләәй улы, Ләәй Галиб улы, Галиб Фәхернең улы, Фәхернең чын исеме Кораеш, Кораеш Мәлик улы, Мәлик Надыйр улы, Надыйр Кинан улы, Кинан Хөзәймә улы, Хөзәймә Мөдрикә улы, Мөдрикә Ильяс улы, Ильяс Мөдәр улы, Мөдәр Нәзар улы, Нәзар Мәгадь улы, Мәгадь Гадьнән улы, Гадьнән Исмәгыйль галәйһиссәлам нәселеннән. Әмма Гадьнәннән Исмәгыйль галәйһиссәламгә кадәр фәлән фәләннең улы, дип билгеләүдән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тыйды. «Кәзбүн-нисәбүн» дип, ягъни нәсеп итүчеләр ялганлыйлар, дип баш тартып, мәкруһ күрә иде. Шуның өчен Рабгузый риваятенчә зекер итмәдек.

Безгә пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмне Исмәгыйль галәйһиссәлам нәселеннән дип белү дә җитәдер.

…Көннәрдән бер көнне Вәһеб үзенең хатыны Бәррагә: «Әминәне Габдуллага хатынлыкка бирәсеңме?» – диде. Бәрра: «Әйе, бирермен», – диде. Бу заманда Аллаһының хикмәте Габделмотталиб улы Габдулла өчен Вәһебкә яучы җибәрде. Вәһеб мең шөкер белән кабул итте. Раҗәб аенда җомга кичне туй иттеләр. Зөфаф шул ук кичтә булып, Әминә йөкле булды. Ибне Габбас радыяллаһу ганһе әйтте: «Бу кичә Кораеш кабиләсендә булган һәр җанвар сөйләшеп, бер-берсенә: «Мөхәммәд бу көнне ана карынына төште», – дип сөенеч бирделәр». «Кәгъбәнең Раббысы белән ант итеп әйтәбез, ул Мөхәммәд дөньяның иминлегедер, ата-бабасының нурыдыр», – диделәр. Иблис мәлгунь Әбү Кәбис тавына менеп кычкырды. Шәйтаннар: «Ни булды сиңа, әй, хуҗабыз?» – дип янына җыелдылар. Иблис: «Аһ, минем ничә еллар чиккән мәшәкатем, бу көнне Мөхәммәд ана карынына төште, Аллаһы Тәгалә аны үткен кылыч белән җибәрер, диннәрне үзгәртер, потларны сындырыр», – диде. Хисәбине Сәбит радыяллаһу ганһе әйтте: «Мин җиде яшемдә идем, Мәдинә урамында бер яһүди: «Әй, яһүдиләр, бу кичтә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең йолдызы туды», – дип кычкырды. Әминә әйтте: «…Улым Мөхәммәдкә йөкле булгач, бер нур күрдем, мәшрикъ һәм мәгъриб яктырды, хәтта Шам вилаятендә Басра шәһәренең сарайларын күрдем…»

Мәшһүр риваятькә нигезләнеп әйтелгәнчә, Әминә радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән йөкле булганның икенче аенда Габдулла атасы Габделмотталибның йомышы белән барган иде, шунда вафат булып, Мәдинәдә күмелде. Атасы үлгәч, фәрештәләр әйтте: «Йә, Раббым, пәйгамбәрең ятим булып калды». Аллаһы Тәгалә әйтте: «Мин аның саклаучы Хуҗасы һәм җиңү бирүчедер». Әминә радыяллаһу ганһә әйтте: «Улымның туу киче җиткәч, дүшәмбе кич таң алды иде. Күктән бер төркем җәмәгать төште. Аларның өч әләме бар иде: берсен Кәгъбәтулланың өстенә, икенчесен үз йортымның түбәсенә, өченчесен Бәйт Әл-Мөкаддәскә кададылар. Йолдызлар шулкадәр якын килде, хәтта үземә төшәр, дип уйладым. Күк ишекләрен тәмам ачык күрдем. Моннан соң өемнең эче зәбәрҗәт борынлы кошлар белән тулды. Дөнья яп-якты булды. Күк белән җир арасында ефәк палас түшәлгән итеп, шулай ук һавада кулларына алтын токталы көмеш комганнар токкан ир кешеләрне күрдем. Шул заман сусадым, шул комганнарның берсеннән су эчтем. Үзем уйлап ятамын, ялгызлыктан күңелем зарыкты, шулчак яныма бер төркем хатын-кыз керде. Шулкадәр матурлар, берсе Асия иде, ул да ярдәм итте. Тулгаклап әчем авыртты, бер кош килеп, канаты белән корсагымны сыйпады, шулчак улым Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне тудырдым, мөбарәк ике аягы белән туды, ягъни йөзтүбән тумады. Бу аның Аллаһы Тәгалә хөкемендә туры булуына ишарә иде. Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм тугач, теле белән: «Аллаһү әкбәр, Аллаһү әкбәр кәбиран, әлхәмдү лилләһи раббилгааләмиин», – диде.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе атасы Габбас радыяллаһу ганһедән, ул үз атасы Габделмотталибтан риваять кылып әйтте: «Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм анасыннан сөн-нәтле һәм кендеге киселгән булып туды». Риваятьләрдә әйтелгәнчә, пәйгамбәрләрдән сөннәтле булып дөньяга килгән пәйгамбәрләр: Адәм галәйһиссәлам, Шис галәйһиссәлам, Идрис галәйһиссәлам, Нух галәйһиссәлам, Лут галәйһиссәлам, Йосыф галәйһиссәлам, Муса галәйһиссәлам, Шөгаеб галәйһиссәлам, Сөләйман галәйһиссәлам, Яхъя галәйһиссәлам, Гайсә галәйһиссәлам, Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм иде».

Әминә радыяллаһу ганһә әйтте: «Мөхәммәд галәйһиссәламне тудыргач, айга охшаган бер кеше улымны алып китеп, бер сәгать юк булып торды. Моннан соң яныма китереп: «Улыңны ал, бер сәгать мәшрикъ һәм мәгърибкә тәваф кылды, Адәм галәйһиссәлам янына барды, Адәм галәйһиссәлам ике күзе арасыннан үбеп: «Сөенеч сиңа, әй, минем дустым, син әүвәлге һәм ахыргы балаларымның хуҗасы», – диде. Моннан соң янә бер кешене күрдем, ул: «Әй, дөньяның хөрмәтлесе, Ахирәтнең шәрифлесе, беркем синең сүзеңне сөйләсә, синең шәһадәтең белән шәһадәт бирсә, Кыямәт көнне синең гыйлемең астында булыр», – диде. Ибне Габбас радыяллаһу ганһе әйтте: «Ул оҗмах сакчысы Ридван иде. Аллаһының әмере белән Расүлуллаһның аркасына пәйгамбәрлек мөһерен ул басты». Габделмотталиб әйтте: «Мин ул кичтә Кәгъбәтуллада идем. Кәгъбә авышып, мәкам Ибраһим тарафына сәҗдә кылды. Потлар куйган урыннарыннан егылып төштеләр. Кәгъбәтулладан тавыш ишеттем: «Аллаһү әкбәр, Аллаһү әкбәр, гөнаһлардан пакь булучы туды. Мөхәммәд галәйһиссәлам мине Раббым мөшрикләрнең нәҗесеннән пакь кылды», – дип ишеттем.

…Әминә радыяллаһу ганһә әйтте: «Мөхәммәдне тудыру кичендә өйнең түбәсе күтәрелде, һавада шулкадәр матур кызлар күрдем, матурлыкта тиңдәшләре юк. Габдемәнәф кызларына охшаганнар. Гаҗәпсенеп карап торганда, берсе әйтте: «Кайчанга кадәр гаҗәпсенеп карарсың. Без барчабыз да синең хезмәтчеләрең. Гаден җәннәтеннән сиңа хезмәт итәргә килдек», – диделәр. Акылымнан яздым, һушыма килгәч, баламны тудырган идем. Улымның бер кулын күзенә, икенче кулын ят әгъзасына куйганын күрдем, шул хәлдә сәҗдә кылды. Колагымны салып тыңладым. «Өммәтем, өммәтем», – дип әйтә иде. Шулвакыт күземнән югалды. Кая киттең улым, дип торганда, бер ак болыт улымны китереп, яныма куйды. Улымны юганнар, күзенә сөрмә тартылган, хушбуй сипкәннәр һәм ефәккә чорнаганнар. Шулвакыт Гатикә кереп: «Әй, Әминә, ни хәлең бар?» – диде». Әминә булган хәлләрне баштан аяк сөйләп бирде. Гатикә әйтте: «Сөйгәнемнән сикереп тордым, кайда ул Мөхәммәд дип, кулыма алып кочакладым. Шулкадәр хушбуйлы, андый ләззәтле хушбуй күргәнем юк иде. Йөзен ачып карадым, әйтерсең, тулган ай иде. Ул төн шундый төн иде, дөньяның әүвәленнән ахырынача андый төн булмады. Кәгъбәдә өч йөз алтмыш пот бар иде, барчасы җиргә төштеләр».

…Габделмотталиб пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына кергәннән соң, чын пәйгамбәрне күрде. Мөхәммәд галәйһиссәлам бабасын күреп, имән бармагын күтәреп, кәлимәи шәһадәт әйткән кебек ишарәләде. Габделмотталиб бу кәрамәтләрне күреп бик шатланды. Кулына күтәреп, Кәгъбә шәрифкә алып керде. Ихлас нияте белән Аллаһы Тәгаләгә мондый бала биргәне өчен шөкер итеп, дога кылды. Җиде көннән соң Мөхәммәд дип исем куштырып, Мәккә халкын җыеп сыйлады, кадер-хөрмәт кылды.

■ **«Кыйсасел-әнбия. Пәйгамбәрләр тарихы» китабыннан**

# Император гаиләсенең шәхси кучеры

## Әҗе авылыннан булган татар кешесенең император гаиләсендә кучер булып хезмәт итүе

Белүебезчә, революциягә кадәр Царское село һәм Патша Сараенда император йортында билгеле бер вазифалар башкаручы татарлар хезмәт иткән. Аларны барыннан да бигрәк хезмәт сөючән, аз сүзле, намуслы һәм пөхтә булганнары өчен яратканнар. Татар хезмәтчеләре янәшәсендә төрле мәсьәләләр хакында сөйләшә алганнар, чөнки Романовлар сөйләнгәннәрнең читкә чыкмавына тулысынча ышанган.

1856 елны Әҗе исемле татар авылында (хәзерге Рязань өлкәсе), ярлы крестьян гаиләсендә туып үскән Сәйфулла Хәбибулла улы Борнашевның тормышы аеруча да игътибарга лаек. Әҗе XX гасыр башында зур авыл булган. Биредә җиде мәчет һәм ике мөселман мәктәбе эшләгән.

Гаилә әһелләренең сөйләвенчә, авылның бер имамының улын хәрби хезмәткә алырга тиеш булганнар. Ул Сәйфулла Борнашевның әтисе Хәбибуллага, үз улын җибәрсен өчен, 25 көмеш тәңкә акча тәкъдим иткән. Хәбибулла әфәнде моңа ризалашкан.

Сәйфулла уртача буйлы кешедән озынрак гәүдәле, төз, киң җилкәле, кара чәчле, өстәвенә, атта оста йөри белүче кеше була. Үзенең билгеләре белән ул тулысынча гусарлар өчен куелган таләпләргә туры килә, һәм, нәтиҗәдә, гусарлар полкына алына. Армия сафларында хезмәт иткәндә Сәйфулла Борнашевка Николай IIнең абыйсы, император Александр IIнең улы – бөек князь Алексей Александр улы игътибар итә. Ул аны үзенә кучер итеп хезмәткә ала.

Уңайлы булсын өчен князь үзенең кучерын русчалаштырып, Степан Николаевич дип йөртә башлый. Алексей Александр улы үзе зиннәтле сарайда яши, флот адмиралы дәрәҗәсендә санала һәм Рәсәй империясенең иң бай кешеләренең берсе булып тора.

Ул Сәйфулланы эшне төгәл башкаруы өчен генә түгел, баһадирдай гадәттән тыш көче һәм тугрылыгы өчен хөрмәт иткән, дип әйтәләр. Әмма, моннан тыш, Сәйфулла Борнашев горур холыклы кеше була. Берьюлы ул, бөек князь сәфәрдә булганда князьнең утарында идарә итүче белән бәхәскә керә һәм барысын да ташлап, үзенең туган авылы Әҗегә кайтып китә. Моның хакында белгән князь Мәскәү генерал-губернаторына Сәйфулла Борнашевны эзләп табуларын сорап телеграмма җибәрә. Нәтиҗәдә, аны табып Петербургка кайтаралар. Моннан соң Алексей Александр улы еш кына Сәйфулла Борнашевка карап: «Йә, Степан, оят түгелме сиңа, мин китәргә дә өлгермәдем, ә син югалгансың», – дип әйтә торган була.

Сәйфулла Борнашев куе кара сакаллы кеше иде. Иң мөһим атрибутларының берсе: Романовлар династиясе бүләк иткән, Рәсәй империясе гербы төшерелгән алтын чылбырлы сәгать булган. Невский проспекты буйлап йөрергә чыккан Сәйфулла Борнашев чуклы төрек баш киемен кигән. Бу бик күпләрнең игътибарын җәлеп иткән.

Сәйфулла Борнашевның сигез улы була. Һәрберсенең тууыннан соң Алексей Александр улы үзенең кучерын 50 сум акча белән бүләкли торган иде. Үз вакытына күрә бу зур акча була. Петербургта С. Борнашев йортның тулы бер катын биләп торган биш залл киң фатир булдыра. Ул балаларын укытуга зур әһәмият бирә. Аларны тәрбияләр өчен татар милләтеннән булган махсус гувернантка яллана.



Сәйфулла Борнашев (А.Б. Беляевнең шәхси архивыннан)



Равилә Хәлил кызының яшь вакыты

1908 елда бөек князь Парижда грипп авыруыннан үлә. Үлеме алдыннан үзен кучер Степан җирләвен васыять итеп калдыра. Һәм император Николай IIгә киләчәктә кучерын үзенә хезмәткә алырга куша. Император бу үтенечне үти: Сәйфулла Борнашев Николаю IIгә кучер булып билгеләнә. Патша аны бик юмарт бүләкли һәм ул эшләп тапкан акчаларына Әҗедә ике катлы йорт төзи һәм тегермән сатып ала. Бу аны лаеклы ялга чыкканнан соң да җитеш тормыш белән тәэмин итәргә тиеш була.

Әмма 1917 елда килеп чыккан революция бик күпләрнең тормышын үзгәртә. Рәсәйдән күченеп китәргә чакыруларына карамастан, Сәйфулла Борнашев туган иленнән китми. Ул җыйган малының күп өлешен югалта, тик үзенең эшенә тугры кала. Моннан соң ул император каретасы белән түгел, совет хөкүмәте әгъзаларының пролеткасы белән идарә итә. Сәйфулла Борнашев 1933 елда 77 яшендә вафат була. Аны туган авылы Әҗенең мөселман зиратында җирлиләр.

Моның белән Сәйфулла Борнашев гаиләсенең тарихы тәмамланмый. Әгәр ул үзе Рәсәй империясенең соңгы императорында кучер булып хезмәт итсә, аның икенче улы – Вәли Борнашев Совет Рәсәенең беренче җитәкчесе Владимир Ленинның шәхси шоферы була. Ә ике оныгы: Тәлгать (Вәли Борнашевның улы) һәм Җәгъфәр (Хәлил Борнашевның улы) очучылар булып, Бөек Ватан сугышы вакытында хәрби очкычлар белән идарә итә. Ә оныгы Равилә Хәлил кызы Борнашева медицина фәннәре докторы, Татарстанда танылган табиб-аллерголог була. Ул Казан Аллергология мәктәбенә нигез сала.


**■ Мөхсин Нурулла язмасы, Islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә**



Сәйфулла Борнашев гаиләсе (А.Б. Беляевнең шәхси архивыннан)




Әҗе авылы (хәзерге Рязань өлкәсе)



# Хакыйкый кол

Берьюлы Ибраһим бине Әдһәм кол сатып алганнан соң аннан болай дип сораган:

– Син нәрсә ашыйсың (Нинди ризык яратасың?)

– Нәрсә бирсәгез шуны ашыйм.

– Синең нинди эш башкарасың килә?

– Нинди эш бирсәгез, шуны башкарам.

– Синең берninди дә теләгең юкмы әллә?

– Әллә колның үзенең хуҗасының теләгеннән өстен булган берәр теләге бармы?

Бу сүзләрне ишеткән Ибраһим бине Әдһәм үзенә: «Ий бәхетсез! Үз гомереңдә бер тапкыр да син Раббың белән шул рәвешле булмадың», – дип әйткән.

**Нәсыйхәт:**

Кеше – Аллаһы Тәгаләнең колы. Шуңа күрә ул үзенең нәфесләреннән һәм теләкләреннән баш тартырга һәм Аллаһының әмерләрен үтәп, Аның ихтыярын барысыннан да өстен куярга тиеш.

Имам Раббани болай дип әйткән: «Аллаһы Үзенең әмерләрен кичектермичә үтәүче колларын ярата. Раббысының әмерләрен үтәүдә сүлпәнлек күрсәтү итагатьсезлек һәм хөрмәт итмәүне белдерә».

**«Әллә кеше караучысыз калдырылган [үлеме артыннан терелтеләп, җәзаландырылмас] дип саныймы?»**

«Кыямәт», 75:36

# Үлчәүләрдә хәйләкәрлек күрсәтү

Мәлик бине Динар рахимәһуллаһи болай дип сөйләгән: «Мин үлем түшәгендә ятучы күршемнең хәлен белергә кердем. Аның хәлләрен соравыма ул:

– Ий Мәлик! Минем каршымда уттан ике тау тора һәм минем аларга менүемне телиләр, – дип әйтте.

Боларны ишеткәннән соң мин гаиләсеннән:

– Һичшиксез, бу халәтнең аңлатмасы булырга тиеш. Бу кеше нишли иде? – дип сорадым. Алар:

– Аның ике үлчәве бар иде. Берсендә сатасы әйберен, икенчесендә сатып аласы әйберен үлчи торган булды, – дип җавап бирделәр.

Мин ул үлчәүләрне алып килергә куштым. Гаилә әһелләре үлчәүләрне китергәч, берсенә берсен сугып, аларны ваттым да күршемнән хәзер хәле ничек булуын сорадым. Ул:

– Хәзер хәлем тагын да начарланды, – дип әйтте.

**Нәсыйхәт:**

**«Киметеп үлчәүчеләргә ни үкенеч! Алар [үзләре өчен] кешеләрдән үлчәткән вакытларында, тулысынча алалар. Ләкин аларга үлчәгәндә яки [бизмәнгә салып үлчи торган нәрсәләрнең] авырлыгын билгеләгәндә, киметәләр».**

«Мутаффифин / Киметүчеләр», 83:1-3

# Үз кулларың белән кәсеп ителгән ризык

Берьюлы Давыд галәйһиссәлам дәүләттәге хәлләр турында сөйләшергә кеше табу нияте белән урамга чыккан. Шулвакыт Җәбраил галәйһиссәлам Давыд галәйһиссәлам каршысына кеше кыяфәтендә килеп баскан. Давыд галәйһиссәлам аны танымыйча:

– Дәүләт белән идарә итүдә Давыдның ысуллары турында нәрсә уйлыйсың? – дип сораган.

Фәрештә:

– Давыд бик яхшы кеше, әмма аның бер җитешсезлеге бар. Әгәр ул булмаса, ул тагы да яхшырак булыр иде, – дип әйткән.

Давыд галәйһиссәлам:

– Нәрсә ул? – дип сораган.

Ул:

– Ишетүемчә, ул үзенә диган чыгымнарны Бәйтел-малдан ала. Үз кулларың белән кәсеп итеп алган әйбердән дә яхшырагы юк, – дип әйтә.

Давыд галәйһиссәлам өенә кайтып, үз куллары белән кәсеп итүне сорап, Аллаһыга дога кыла.

Моңа сорау буларак Аллаһы Тәгалә тимерне йомшарта һәм Давыд пәйгамбәр көбә ясап, шуны сата торган була.

**Нәсыйхәт:**

Җитәкче кешенең үзенең кул астында булучыларның аннан риза булу-булмаулары хакында белүе мөһим. Гомәр радыяллаһу ганһе кайвакытта ялгызы, ә кайчакларда берәрсе белән төнге Мәдинә буйлап йөри торган иде.

# Файдасыз гыйлем

Вәһеб бине Мөнәббиһ рахимәһуллаһи болай дип әйткән: «Исраил угылларыннан булган бер галимнең китаплар белән тулы 70 сандыгы булган. Һәрбер сандыкның озынлыгы 70 терсәк озынлыгы иде. Аллаһы Тәгалә шул чорның пәйгамбәренә түбәндәге вәхине индергән: «Әлеге галим янына барып, аңа болай дип әйт: «Синең өч үзенчәлегең бар: дөнья тормышына мәхәббәт, шәйтаннар белән дуслык һәм мөселманнарга тынычсызлык китерү. Син алардан азат булмыйча, гыйлемнәрең синә берни дә файда китермәячәк».

**Нәсыйхәт:**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дөнья тормышына мәхәббәт – барлык хаталарның башы», – дип әйткән.

Гыйлемне гамәлгә кертеп җибәрү мөһим. Бу гамәлләрне ихлас күңелдән башкару мәҗбүри шарт булып тора. Ихлассыз башкарылган гыйлем берninди әҗер-савап китермәячәк, ә киресенчә, гөнаһка төшүнең сәбәбе булырга мөмкин.

Дөнья тормышын һәм дөнья нигъмәтләрен Аллаһы ризалыгына ирешер өчен куллануда берninди дә каршылык юк.

«Рухуль Бәйан» китабыннан

# Намаз кайсы вакытларда укыла?

Биш вакыт фарыз намаз бар: иртәнге намаз, өйлә намазы, икенде намазы, ахшам намазы һәм ястү намазы. Һәр намазның үтәлер өчен билгеләнгән вакыты бар. Намазны үз вакытында уку – аның мәҗбүри шартларының берсе. Намазны вакытыннан алда укырга ярамый, ә вакыты чыкканнан соң укылган намаз – каза була. Коръәни Кәримдә болай дип әйтелгән:

**«...намазны [әмер ителгән шәкелдә] кылыгыз. Һичшиксез, намаз кешеләргә вакыты билгеләнеп фарыз кылынган».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:103

Намазның вакытлары турында Аллаһы Тәгалә Коръәндә: **«Кичкә кергән чагыгызда [ахшам-ястү намазларын укып] һәм таңга кергән чагыгызда [иртәнге намазны укып, төн һәм көн нигъмәтенә шөкер өчен] Аллаһы – пакь [дип мактагыз]. Күкләрдә һәм җирдә булган барча мактау – Аңа гына, көннең ахырында да [икенде намазын], өйләгә кергәч тә [өйлә намазын укыгыз]»**, – дип әйткән.

«Әр-Рум / Румлылар», 30:17-18

Иртәнге намазның вакыты таң атканда көнчыгыш тарафта офыкка параллель рәвештә ачык төстәге бер сызык хасил булу белән башлана һәм офык өстендә кояш дискының кырые күренгәч тәмамлана.

Өйлә намазының вакыты кояш зенитка күтәрелеп көнбатышка тайпылганнан соң күләгәләр көнчыгышка таба озыная башлагач керә. Бу вакыт барлык әйберләрнең күләгәсе үзе кадәр ике озынлыкка җиткәнче дәвам итә (төп күләгә озынлыгын санамыйча).

Икенде намазының вакыты өйлә намазының вакыты тәмамлануга ук башлана һәм кояш тулысынча баеганга кадәр дәвам итә.

Ахшам намазының вакыты кояш баегач башлана һәм шәфәкъ беткәнчегә кадәр дәвам итә.

Ястү намазының вакыты ахшам намазының вакыты беткәч башлана һәм иртәнге намазның вакыты кергәнчегә хәтле дәвам итә.

Витр намазының вакыты ястү намазының вакыты белән бер. Витр намазы ястү намазыннан соң укыла.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Вакытының башында укылган намазда Аллаһының ризалыгы бар, ә вакытының ахырында кылынган намазда Аллаһының ярлыкавы бар».

Җомга намазының вакыты җомга көннең өйлә намазы вакытына туры килә.

Тәравих намазының вакыты – Рамазан ае буенча ястү намазының вакыты.

Бәйрәм намазының вакыты кояш чыгып якынча 30 минут узгач башлана һәм кояш зенитка күтәрелгәнчегә кадәр дәвам итә.




Намаз кылу мәкруһ булган вакытлар

Тәүлек эчендә намаз кылынмый торган вакыт аралары бар:

1. Кояш чыккан вакытта.
2. Зәвәл вакытында.
3. Кояш батканда.

**Искәрмә:** Иртәнге намазның вакыты кергәч, шул намазның сөннәте белән фарызыннан кала башка намаз укылмый. Һәм шулай ук икенде намазының фарызыннан соң нәфел намазлары укылмый.

Кояш баеган вакытта, әгәр дә ул укылмаган булса, бары тик шул көннең икенде намазын гына кылырга ярый.

# Кемнәр намаз укырга тиеш?

Намаз – Исламның биш терәгенең берсе һәм шунлыктан намаз уку барлык мөселманнар өчен әмер ителгән.

Өч шартка туры килгән кеше намаз укырга тиеш:

1. Мөселман булган.
2. Балигълык яшенә җиткән.
3. Тулы акылы булган.

Кешеләрнең иң төп вазифасы – Аллаһының барлыгына һәм берлегенә, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең пәйгамбәрлегенә ышану. Мөэминнәрнең иң мөһим гыйбадәте исә – намаз уку.

Намазның Аллаһы каршындагы әһәмияте турында түбәндәге вакыйгалар әйтеп тора: Исламның нигезләрен үтәргә кирәклеге турындагы әмерне Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Җәбраил галәйһиссәлам аркылы җиткерсә, намаз укырга кирәклеге турындагы әмерне Аллаһы Тәгалә турыдан-туры Үзе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә мигъраҗ вакытында хәбәр иткән!

Кешеләргә биш вакыт намаз уку, һиҗрәткә кадәр бер ел ярым кала, Мигъраҗ кичендә фарыз булган.

Намаз җанны сафландыра, күңелне нурландыра, кешене Аллаһы каршында зурлый торган гыйбадәт.

Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Намаз – диннең бер терәгедер. Кем намазны калдырса, шул үз динен җимерә», – дип әйткән.

Бервакыт пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләреннән болай дип сораган: «Өегез каршыннан аккан елгада көнгә биш тапкыр коенсагыз, тәнегездә кер калырмы?» Сәхабәләр: «Йә, Аллаһының Расүле, бернинди кер дә калмас», – дип җавап биргәннәр. Шуннан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Биш вакыт намаз да шуның сыман: Аллаһы Тәгалә намаз белән гөнаһларны юып төшерә», – дип әйткән.

Намаз кеше күңелендәге тәкъваны арттырып, Раббыбызга карата сөюне көчәйтеп, безне гөнаһлы гамәлләрдән саклый. Моның турыда Коръәни Кәримдә болай дип әйтелгән:

**«[Расүлем!] Сиңа вәхи ителгән Китапны [Аллаһы Тәгаләгә рухи яктан якынаю, сүзләрен ятлау һәм мәгънәләрен бик яхшы аңлау өчен] укы һәм [фарыз] намазны укы, чөнки [тышындагы һәм эчендәге бөтен шарт һәм әдәпләренә туры китереп, камил дәрәҗәдә укылган] намаз [зина кебек] әшәкелекләрдән дә, [шәригатьтә дә, акыл белән дә] гаеп саналганнардан да саклый. Аллаһыны зикер итү [өчен кабул ителгән һәм бөтене белән зикердән гыйбарәт булган намаз] исә [калган барлык гыйбадәтләрдән дә] өстенрәк. Аллаһы сезнең ни кылганнарыгызны белә».**

«Әл-Ганкәбут / Үрмәкүч», 29:45

Мөселман кеше үзе намазларын кылырга бурычлы булган кебек, балаларын да намазга өйрәтергә бурычлы. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөселманнарга балаларын җиде яшьтән алып намазга күнектерергә тәкъдим иткән, бу аларда Исламның әлеге нигезенең әһәмиятен аңлау өчен кирәк.

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Балагыз җиде яшенә җитүгә аннан намаз кылуын таләп итә башлагыз. Ун яшенә кергәндә намаз кылмыйлар икән, аларга моның өчен җәза бирегез. Бүлмәләрендә аларга аерым ятак хәзерләгез», – дип әйткән.

Намаз укымаган кеше дингә карата йокыга талган сыман һәм әгәр дә тәүбә итеп бу эшеннән туктамаса, аны җәзалар көтә. Һәм ул Кыямәт көнендә яклаучысыз калачак, шәфәгатьтән мәхрүм булачак. Коръәни Кәримдә болай дип әйтелгән:

**«[Алар] Җәннәтләр эчендә берберләреннән сорашачаклар. Гөнаһлылар хакында [аннары араларындагы пәрдә ачылгач, әйтерләр]: «Сезне Сәкарга нәрсә кертте?» [Җәһәннәм әһеле] Әйтер: «Без намаз укучылар түгел идек».**

«Әл-Муддәссир / Төренгән», 74:40-43

Намаз укымаган мөселман гөнаһлы кеше була, ләкин мөселман булудан туктамый. Ә намазны укырга кирәкми дип санаса, диненнән кайткан була.

Кодси-хәдистә әйтелгән: «Мин синең өммәтеңә биш вакыт намазны бурыч иттем. Аны үз вакытында кылган кешеләр өчен җәннәтне вәгъдә иттем, ә кылмаганнар өчен бернәрсә дә вәгъдә итмәдем».

■ **dumrt.ru сайтыннан**

# Сихерчелек

Шәйтанның кешеләргә сихер өйрәтүенең бер генә максаты бар – аларны Аллаһы Тәгаләдән ваз кичтерү. Сихерченең имансыз икәнендә бернинди дә шик юк.

Аллаһы Тәгалә Һарут һәм Марут турында «Әл-Бәкара» сүрәсендә болай дип әйтә:

**«Алар [Аллаһы Тәгаләнең китабын артларына ташлап] Сөләйман галәйһиссәламнең падишаһлыгы [чорында] шәйтаннарның укып йөргән нәрсәләренә [сихергә] ияргәннәр. Тик Сөләйман [галәйһиссәлам] кяфер түгел иде, кешеләргә сихерне һәм Бабил илендәге ике фәрештәгә – Һарут белән Марутка иңдерелгән нәрсәне өйрәтеп, шәйтаннар кяфер булдылар. Хәлбуки, ул икәү [Һарут белән Марут]: «Без сезгә фетнә [һәм сынау] бит, сез [бу сихерне өйрәнеп, хәләл булмаган нәрсәләргә ышанып] кяфер булмагыз!» – дип әйтми торып, беркемне дә өйрәтмиләр иде. Алар [кешеләр] ир белән хатын арасын аера торган [сихер кебек] нәрсәләрне шул икәүдән өйрәнгәннәр иде, тик алар [сихер ясаучы кешеләр], Аллаһының рөхсәте булмыйча, аның белән һичкемгә дә зарар китерә алмаячаклар ...»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:102

Бу юлдан баручыларны бүгенге көндә дә күрергә мөмкин. Алар уйлавынча, моның белән шөгыльләнү харам дәрәҗәсендә генә. Әмма алар моның ширек икәнен һич аңламыйлар. Алар алхимияне өйрәнеп, шуны кулланырга телиләр (Алхимия – сихернең бер төре. Аның төп максаты – дөньяда әле булмаган берәр нәрсә уйлап табу). Кемдер сихерне никахларны бетерү өчен, кемдер берәр ир хатынын ярата башласын өчен куллана ала. Кемдер (сөйдергеч сихер кулланып) бер кешене икенче кешегә гашыйк итәргә тырыша. Болар барысы да ширек һәм адашу.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Һәлакәткә китерә торган җиде гөнаһтан сакланыгыз: ширек кылу, сихерчелек, кеше үтерү, ятимнең малын ашау...», – дип әйткән, ягъни җиде зур гөнаһ арасында сихерчелекне дә искә алган.

Кеше үзенең раббысы Аллаһыдан куркырга һәм бу дөньясын да, теге дөньясын да җимерә торган юлдан бармаска тиеш.

Әбү Муса радыяллаһу ганһедән риваять кылына: Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Өч төркем кеше җәннәткә кермәячәк: эчкече, туганлык җепләрен өзүче, сихерченең сүзләренә ышанучы кеше», – дип әйткән (Әбү Давыд һәм Ибне Мәҗе хәдисләр җыентыгыннан).

Кызганыч, әмма өммәтебезнең күпчелеге бу мәсьәләләрдә гыйлемсез. Шуңа күрә моны бераз гына аңлатып китәргә кирәктер, чөнки зур гөнаһлар өчен җәзасы да көчле була.

... Гөнаһлы гамәлләрнең һәлакәткә китерүен аңлаган һәм аннан читләшкән; фарыз гамәлләр турында гыйлем алган һәм аны үтәгән кеше бәхетле була. Әмма андый кешеләр аз очрый. Ә андый гыйлемне алган кеше Аллаһы Тәгаләгә хәмед әйтергә, рәхмәтле булырга тиеш.

Әйе, кеше турында: «Ул нәрсәләр кылырга кирәклеге турында гыйлем алырга теләмәде, шуңа күрә үзе гаепле», – дип әйтергә мөмкин. Әмма бу хакыйкатькә бик үк туры килми: «Гади кешегә гыйлем алырга кирәклеге мәгълүм булмаска да мөмкин. Аллаһы Тәгалә кешегә берәр төрле гыйлем бирмәсә, ул кеше өчен бу гамәлне кылу фарыз булмаячак. Әмма ул гыйлемне алу белән, кеше бу гамәлләрне кылырга тиеш була.

Рәхимле һәм Рәхмәтле Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«... Без, бер расүл җибәрми торып, газап бирмәдек».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:15

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең кайбер сәхабәләре Хәбәшстанга һиҗрәт кылганнар иде. Бу вакытта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә кылырга яраган һәм ярамаган гамәлләр турында гыйлем иңә генә башлады. Ә һиҗрәт кылган кешеләргә бу гыйлем берничә айдан соң гына иреште. Шуңа күрә, аларга барып ирешкәнче, җитди сәбәп аркасында, алар кылган гөнаһлары өчен җавап тотмадылар. Бу барлык очракларда да кулланыла ала: кешегә дини канун килеп ирешкәнче, ул аның өчен җавап тотмаячак. Ә Аллаһы Тәгаләгә исә яхшырак мәгълүм.

# Намазга игътибар итмәү

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Аларның артыннан яшь буын килде, алар [фарыз намазларга ышанмыйча, тәмам кире кагып, казага калдырып] намазны югалттылар һәм [исерткеч, зина кебек харамнар эшләп] шәһвәтләргә иярделәр. Һичшиксез, алар яманлык белән очрашачаклар. Тик [намаздагы кимчелекләрдән һәм башка гөнаһлардан] тәүбә иткән, иман китергән һәм [бу иманы кушканча] изге гамәлләр кылган кешеләр генә түгел. Болар җәннәткә керәчәкләр һәм берни белән дә рәнҗетелмәячәкләр».**

«Мәрьям», 19:59-60

Шулай ук:

**«Намаз укыганнарга [монафикъларга] ни үкенеч! Намазларында гафилләргә».**

«Әл-Мәгүн / Изгелек кылу», 107:4-5

Шулай ук Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә мондый аять тә китерә:

**«Сезне Сәкарга нәрсә кертте?» [Җәһәннәм әһеле] Әйтер: «Без намаз укучылар түгел идек».**

«Әл-Мүддәссир / Төренгән», 74:42-43

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм имам Бохари хәдисләр җыентыгында килгән түбәндәге хәдисне әйтеп калдырган: «Икенде намазын укымыйча калдырган кешенең гамәлләре юкка чыгарылачак».

«Аллаһы Тәгалә намазларын үз теләге белән калдыра башлаган кешене саклаудан, яклаудан туктый» (Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан).

Гомәр Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе: «Намазын кадерсезләгән кешенең ислам белән уртаклыгы юк», – дип әйтә.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең түбәндәге сүзләрен җиткерә: «Мөселман кешедән Кыямәт көнендә иң беренче соралачак нәрсә – ул аның намазы. Әгәр дә ул аны тиешенчә үтәгән булса, аны котылу көтә, шулай булмаганда исә (тиешенчә үтәлмәгән очракта), ул өметен югалтачак һәм аны канәгатьсезлек көтәчәк» (Имам Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан).

Габдулла бине Гомәр радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең түбәндәге сүзләрен җиткерә: «Намазын кадерсезләгән кешенең нуры да, дәлилләре дә, котылу чарасы да калмаячак. Кыямәт көнендә андый кеше



Карун, Фиргавен, Һаман һәм Гобәй бине Хәләф белән янәшә булачак» (Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан).

Бу кешеләр янында басып тору – намаз укымаучының имансызлыкка никадәр якын булуын да күрсәтә. Әмма пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Могаз радыяллаһу ганһегә түбәндәге сүзләрен әйтә: «Аллаһы Тәгаләдән башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат юк икәнлегенә һәм Мөхәммәд – Аллаһы Тәгаләнең пәйгамбәре икәненә ихлас күңелдән гуаһлык (шаһитлык) китергән һәрбер кешегә Аллаһы Тәгалә җәһәннәмдә булырга юл куймас».

Намазны вакытында кылмау яки аннан баш тарту, караклык яки зина кылу – зур гөнаһлар. Әгәр дә кеше намаздан үз теләге белән берничә тапкыр баш тартса, зур гөнаһлы булачак. Әгәр бу дәвамлы булса һәм кешенең гадәтләренең берсенә әйләнсә, әлбәттә, фасыйк һәм залимнәрдән булыр иде.

■ **Имам Әз-Зәһәбинең «Әл-Кәбаир» китабыннан**

**Хөрмәтле радиотыңлаучылар!**

"Азан" радиосы сайтының адресы үзгәрде. Хәзер безне azan.fm сылтамасы буенча таба аласыз. Иске мобиль кушымталар да үз эшен туктатты, аларны яңарту кирәк. Моның өчен, айфоннарда – App Store, андроидларда Play Market'ка кереп, "Азан радиосы" дип җыеп, "обновить" төймәсенә басарга кирәк. (Әгәр моңарчы телефоныгызда безнең кушымта булмаса, бер дә шикләнмичә куегыз). Әзер! Хәзер сез кая гына барсагыз да, бернинди түләүсез рәхәтләнеп татарча дини радио тыңлый аласыз.

**QR – кодлар:**

Android өчен:

iPhone өчен:

| | |
|---|---|
| **Сайт:** | azan.fm |
| **Инстаграм:** | azan.fm |
| **Вконтакте:** | azanfm |
| **Телеграм-канал:** | azanfm |
| **Почта:** | radio@azan.fm |
| **Тел.:** | 8 (843) 598-09-43 |

### ■ДҮШӘМБЕ, СИШӘМБЕ, ЧӘРШӘМБЕ, ПӘНҖЕШӘМБЕ, ШИМБӘ, ЯКШӘМБЕ

| | |
|---|---|
| 0:00-5:59 | Коръән |
| 6:00-6:20 | Коръән тәфсире |
| 6:30-6:32 | Көндәлек догалар |
| 6:40-6:50 | Таян Аллаһка |
| 6:55-7:00 | Хәзрәткә сорау |
| 7:05-7:15 | Иман тәме |
| 7:20-7:23 | Миллият сүзлеге |
| 7:30-7:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 7:40-7:45 | Әд-дин вә әдәп |
| 8:10-8:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 8:25-8:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 8:50-8:55 | Гыйбадәте Исламия |
| 9:00-9:15 | Күңелдән күңелгә |
| 9:25-9:35 | Тынычлык тәгълиматы |
| 9:45-9:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 10:00-10:15 | Бәхет тулы йорт |
| 10:20-10:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 10:30-10:45 | 101 вәгазь |
| 10:55-10:57 | Көндәлек догалар |
| 11:00-11:15 | 40 хәдис |
| 11:25-11:28 | Миллият сүзлеге |
| 11:40-11:50 | Намаз дәресләре |
| 12:00-12:04 | Азан |
| 12:30-14:00 | Кәлам Шәриф – мәгънәви тәрҗемә |
| 14:05-14:15 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 14:20-14:27 | Мәчетләребез тарихы |
| 14:30-14:40 | Сөннәт юлы |
| 14:45-14:50 | Әд-дин вә әдәп |
| 14:55-15:10 | Әбү Хәнифә (р.г.) |
| 15:15-15:20 | Хәзрәткә сорау |
| 15:25-15:30 | Әхлак баскычлары |
| 15:45-15:48 | Миллият сүзлеге |
| 16:00-16:20 | Коръән тәфсире |
| 16:25-16:27 | Көндәлек догалар |
| 16:30-16:40 | Таян Аллаһка |
| 16:50-17:00 | Иман тәме |
| 17:05-17:08 | Миллият сүзлеге |
| 17:10-17:15 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 17:20-17:25 | Әд-дин вә әдәп |
| 17:50-17:57 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 18:00-18:15 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 18:20-18:25 | Гыйбадәте Исламия |
| 18:30-18:45 | Күңелдән күңелгә |
| 18:50-19:00 | Тынычлык тәгълиматы |
| 19:05-19:15 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 19:20-19:35 | Бәхет тулы йорт |
| 19:40-19:45 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 19:50-20:05 | 101 вәгазь |
| 20:10-20:15 | Көндәлек догалар |
| 20:20-20:35 | 40 хәдис |
| 20:40-20:43 | Миллият сүзлеге |
| 20:45-20:55 | Намаз дәресләре |
| 21:00-21:03 | Нәниләргә нәсыйхәт |
| 21:20-21:30 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 21:40-21:47 | Мәчетләребез тарихы |
| 21:50-21:55 | Хәзрәткә сорау |
| 22:00-22:10 | Сөннәт юлы |
| 22:15-22:20 | Әд-дин вә әдәп |
| 22:25-22:40 | Әбү Хәнифә (р.г.) |
| 22:45-22:50 | Әхлак баскычлары |
| 22:55-22:58 | Миллият сүзлеге |
| 23:00-5:59 | Коръән |

### ■ҖОМГА

| | |
|---|---|
| 0:00-5:59 | Коръән |
| 6:00-6:20 | Коръән тәфсире |
| 6:30-6:32 | Көндәлек догалар |
| 6:40-6:50 | Таян Аллаһка |
| 6:55-7:00 | Җомга тәбриге |
| 7:05-7:15 | Иман тәме |
| 7:20-7:23 | Миллият сүзлеге |
| 7:30-7:35 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 7:40-7:45 | Әд-дин вә әдәп |
| 8:10-8:17 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 8:25-8:40 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 8:50-8:55 | Гыйбадәте Исламия |
| 9:00-9:15 | Күңелдән күңелгә |
| 9:25-9:35 | Тынычлык тәгълиматы |
| 9:45-9:55 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 10:00-10:15 | Бәхет тулы йорт |
| 10:20-10:25 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 10:30-10:45 | 101 вәгазь |
| 10:55-10:57 | Көндәлек догалар |
| 11:00-11:15 | 40 хәдис |
| 11:25-11:28 | Миллият сүзлеге |
| 11:30-11:35 | Җомга тәбриге |
| 11:40-11:50 | Намаз дәресләре |
| 12:00-12:04 | Азан |
| 12:30-14:00 | Кәлам Шәриф – мәгънәви тәрҗемә |
| 14:05-14:15 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 14:20-14:27 | Мәчетләребез тарихы |
| 14:30-14:40 | Сөннәт юлы |
| 14:45-14:50 | Әд-дин вә әдәп |
| 14:55-15:10 | Әбү Хәнифә (р.г.) |
| 15:15-15:20 | Җомга тәбриге |
| 15:25-15:30 | Әхлак баскычлары |
| 15:45-15:48 | Миллият сүзлеге |
| 16:00-16:20 | Коръән тәфсире |
| 16:25-16:27 | Көндәлек догалар |
| 16:30-16:40 | Таян Аллаһка |
| 16:50-17:00 | Иман тәме |
| 17:05-17:08 | Миллият сүзлеге |
| 17:10-17:15 | Гыйбрәтле кыйссалар |
| 17:20-17:25 | Әд-дин вә әдәп |
| 17:50-17:57 | Шәхесләргә шәрехләр |
| 18:00-18:15 | Сак булыгыз! Секталар! |
| 18:20-18:25 | Гыйбадәте Исламия |
| 18:30-18:45 | Күңелдән күңелгә |
| 18:50-19:00 | Тынычлык тәгълиматы |
| 19:05-19:15 | Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) |
| 19:20-19:35 | Бәхет тулы йорт |
| 19:40-19:45 | Гыйбадәттә сәгадәт |
| 19:50-20:05 | 101 вәгазь |
| 20:10-20:15 | Көндәлек догалар |
| 20:20-20:35 | 40 хәдис |
| 20:40-20:43 | Миллият сүзлеге |
| 20:45-20:55 | Намаз дәресләре |
| 21:00-21:03 | Нәниләргә нәсыйхәт |
| 21:20-21:30 | Пәйгамбәрләр тарихы |
| 21:40-21:47 | Мәчетләребез тарихы |
| 21:50-21:55 | Хәзрәткә сорау |
| 22:00-22:10 | Сөннәт юлы |
| 22:15-22:20 | Әд-дин вә әдәп |
| 22:25-22:40 | Әбү Хәнифә (р.г.) |
| 22:45-22:50 | Әхлак баскычлары |
| 22:55-22:58 | Миллият сүзлеге |
| 23:00-5:59 | Коръән |

**Тапшырулар арасында эфирда кыска хәдисләр, нәшидләр һәм мөнәҗәтләр яңгырый*

# КАЗАН ӨЧЕН НОЯБРЬ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Көн Исеме | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы/ ифтар | Ясту намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 01.11.2020 | Якш. | 04:44 | 05:20 | 06:50 | 12:00 | 14:10 | 16:03 | 17:47 |
| 02.11.2020 | Дүш. | 04:45 | 05:22 | 06:52 | 12:00 | 14:08 | 16:01 | 17:45 |
| 03.11.2020 | Сиш. | 04:47 | 05:24 | 06:54 | 12:00 | 14:06 | 15:59 | 17:44 |
| 04.11.2020 | Чәр. | 04:49 | 05:26 | 06:56 | 12:00 | 14:04 | 15:56 | 17:42 |
| 05.11.2020 | Пәнҗ. | 04:51 | 05:28 | 06:58 | 12:00 | 14:02 | 15:54 | 17:40 |
| 06.11.2020 | Җом. | 04:53 | 05:30 | 07:00 | 12:00 | 14:00 | 15:52 | 17:38 |
| 07.11.2020 | Шим. | 04:54 | 05:32 | 07:02 | 12:00 | 13:58 | 15:50 | 17:37 |
| 08.11.2020 | Якш. | 04:56 | 05:34 | 07:04 | 12:00 | 13:57 | 15:48 | 17:35 |
| 09.11.2020 | Дүш. | 04:58 | 05:36 | 07:06 | 12:00 | 13:55 | 15:47 | 17:34 |
| 10.11.2020 | Сиш. | 05:00 | 05:38 | 07:08 | 12:00 | 13:53 | 15:45 | 17:32 |
| 11.11.2020 | Чәр. | 05:01 | 05:41 | 07:11 | 12:00 | 13:52 | 15:43 | 17:31 |
| 12.11.2020 | Пәнҗ. | 05:03 | 05:43 | 07:13 | 12:00 | 13:50 | 15:41 | 17:29 |
| 13.11.2020 | Җом. | 05:05 | 05:45 | 07:15 | 12:00 | 13:48 | 15:39 | 17:28 |
| 14.11.2020 | Шим. | 05:06 | 05:47 | 07:17 | 12:00 | 13:47 | 15:38 | 17:26 |
| 15.11.2020 | Якш. | 05:08 | 05:49 | 07:19 | 12:00 | 13:45 | 15:36 | 17:25 |
| 16.11.2020 | Дүш. | 05:10 | 05:51 | 07:21 | 12:00 | 13:44 | 15:34 | 17:24 |
| 17.11.2020 | Сиш. | 05:11 | 05:53 | 07:23 | 12:00 | 13:42 | 15:33 | 17:22 |
| 18.11.2020 | Чәр. | 05:13 | 05:55 | 07:25 | 12:00 | 13:41 | 15:31 | 17:21 |
| 19.11.2020 | Пәнҗ. | 05:14 | 05:57 | 07:27 | 12:00 | 13:39 | 15:29 | 17:20 |
| 20.11.2020 | Җом. | 05:16 | 05:59 | 07:29 | 12:00 | 13:38 | 15:28 | 17:19 |
| 21.11.2020 | Шим. | 05:17 | 06:01 | 07:31 | 12:00 | 13:37 | 15:27 | 17:18 |
| 22.11.2020 | Якш. | 05:19 | 06:03 | 07:33 | 12:00 | 13:36 | 15:25 | 17:17 |
| 23.11.2020 | Дүш. | 05:20 | 06:05 | 07:35 | 12:00 | 13:34 | 15:24 | 17:16 |
| 24.11.2020 | Сиш. | 05:22 | 06:06 | 07:36 | 12:00 | 13:33 | 15:23 | 17:15 |
| 25.11.2020 | Чәр. | 05:23 | 06:08 | 07:38 | 12:00 | 13:32 | 15:21 | 17:14 |
| 26.11.2020 | Пәнҗ. | 05:25 | 06:10 | 07:40 | 12:00 | 13:31 | 15:20 | 17:14 |
| 27.11.2020 | Җом. | 05:26 | 06:12 | 07:42 | 12:00 | 13:30 | 15:19 | 17:13 |
| 28.11.2020 | Шим. | 05:28 | 06:14 | 07:44 | 12:00 | 13:29 | 15:18 | 17:12 |
| 29.11.2020 | Якш. | 05:29 | 06:15 | 07:45 | 12:00 | 13:28 | 15:17 | 17:11 |
| 30.11.2020 | Дүш. | 05:30 | 06:17 | 07:47 | 12:00 | 13:28 | 15:16 | 17:11 |

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**
*Октябрь саны, №10 (303)*

Баш мөхәррир: **Нәширбанов И.К.**
Мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБАРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2754
Газетага ярты елга язылу бәясе – 156 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 27 нче октябрьдә таратыла.
График буенча бу санга 26 нчы октябрь көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.